# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында

Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында

Татарстан Республикасында гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

КАЗАН
2016

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

*(2013 елның 28 октябрендәге 84-ТРЗ номерлы, 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы, 2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы, 2015 елның 9 апрелендәге 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

Әлеге Закон «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга (алга таба шулай ук – ятим балалар, ятим бала) махсуслаштырылган торак фондыннан махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибен билгели.

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Федераль законның 8 статьясындагы 1 пункты нигезендә түбәндәгеләр махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин ителергә тиеш:

1) социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар яисә социаль яллау шартнамәсе буенча торак урынын яллаучының гаилә әгъзалары булмаган йә торак урыннары милекчеләре булмаган ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар;

2) социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар яисә социаль яллау шартнамәсе буенча торак урынын яллаучының гаилә әгъзалары булган йә торак урыннары милекчеләре булган ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар

арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында алар өчен яшәү мөмкинлеге булмавы әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә танылган очракта.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар аларның яшәү урыны буенча, ә даими яшәү урынын ачыклау мөмкин булмаган очракта, күрсәтелгән затлар ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелә торган мәгариф оешмаларында, медицина оешмаларында, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларында яшәп тору урыны буенча бер мәртәбә махсуслаштырылган торак фондыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан торак урыннары белән тәэмин ителергә тиеш.

*(2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Ятим балаларга торак урыны бирү вакытына тиешле торак пункт чигендә аларның яшәү урыны буенча махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары булмаган очракта, күрсәтелгән затларга аларның ризалыгы белән махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары Татарстан Республикасы чикләрендә башка торак пунктта бирелә.

4. Социаль яллау шартнамәләре буенча яллаучылары һәм яллаучыларның гаилә әгъзалары йә милекчеләре булган ятим балалар моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында Федераль законда билгеләнгән шартлар булганда, шулай ук мондый торак урыннарында түбәндәге затлар яши торган очракларда ятим балалар өчен яшәү мөмкинлеге юк дип таныла:

1) торак урыныннан мөстәкыйль файдалану хокукы булган шушы ятим балаларның гаилә әгъзалары булмаган затлар;

2) уллыкка алу юкка чыгарылган булса, шушы ятим балаларның элеккеге уллыкка алучылары булган затлар;

3) законнарда билгеләнгән тәртиптә хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затлар;

4) хөкем ителүе булган яисә элек хөкем ителгән йә кеше гомеренә һәм сәламәтлегенә, җенси кагылгысызлыкка һәм шәхеснең җенси ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халык сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр кылган өчен җинаять эзәрлекләвенә дучар булган яисә элек дучар ителгән затлар (үзләренә карата реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш);

5) хроник алкоголизм, наркомания белән һәм психик авырулар белән авыручы һәм тиешле медицина оешмаларында исәптә торучы затлар.

*(2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

7 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актларны әлеге Законның үз көченә кергән көненнән алып өч ай дәвамында кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 28 декабре
№ 95-ТРЗ

2 статья. **Махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны алу хокукына ия ятим балалар исемлеген төзү тәртибе**

1. Ятим балаларның законлы вәкилләре махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны алу хокукына ия булган ятим балалар исемлегенә (алга таба – исемлек) ятим балаларны кертү турындагы гаризаларны вәкаләтле органга турыдан-туры үзләре йә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталыннан файдаланып, электрон рәвештә яисә кәгазьдә язылган килеш, ятим балаларга 14 яшь тулган көннән яисә ятим балаларга 14 яшь тулганнан соң аларга торак урыннары бирү өчен Федераль законда һәм әлеге Законда каралган нигезләр барлыкка килгән көннән башлап 30 көннән дә соңга калмыйча тапшыралар.

2. Исемлеккә кертү турындагы гаризаларны вәкаләтле органга шулай ук түбәндәгеләр дә тапшырырга мөмкин:

1) тулысынча хезмәткә сәләтле (эмансипацияләнгән) дип игълан ителгән ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, әгәр алар тулысынча хезмәткә сәләтле дип танылганчы әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә исемлеккә кертелмәгән булсалар, – балигъ яшькә җиткәнче;

2) ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, әгәр алар 18 яшькә кадәр әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә исемлеккә кертелмәгән булсалар яисә үзләренең торак урыннары белән тәэмин ителү хокукын 2013 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлгә ашырмаган булсалар.

3. Исемлеккә кертү турындагы гаризага ятим бала паспортының яисә аның шәхесен таныклый торган башка документының күчермәсе, законлы вәкиленең шәхесен һәм аның вәкаләтләрен таныклый торган документ йә ятим баланың тулысынча хокукка сәләтле (эмансипацияләнгән) булуын таныклый торган документ, шулай ук ятим бала, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала статусын раслый торган документлар, күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыра торган орган тарафыннан ятим баланың Россия Федерациясе территориясендә милек хокукында торак урыны булу-булмавы турында бирелгән белешмә, шулай ук ятим баланың гариза бирү вакытына яшәү урыны йә булу урыны буенча теркәлүен раслый торган документ кушымта буларак бирелә.

*(2014 елның 18 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4. *Үз көчен югалтты.*

*(2014 елның 18 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

5. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән категориягә кертелгән ятим балага кагылышлы документларны тапшырганда өстәмә рәвештә түбәндәге документлар кушымта буларак бирелә:

1) ятим бала моңа кадәр биләп тора торган торак урынына хокук бирүче документның күчермәсе;

2) күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыра торган орган тарафыннан ятим бала моңа кадәр биләп тора торган торак урынында яшәүче барлык гражданнарга Россия Федерациясе территориясендә милек хокукында торак урыннары булу-булмау турында бирелгән белешмә;

3) ятим бала гаиләсенең (булган очракта) составы турындагы документларның күчермәләре;

4) ятим бала биләп тора торган торак урынында яшәү мөмкинлекләре булмауның Федераль законда һәм әлеге Законда билгеләнгән шартларын раслаучы документлар, моңа әлеге Законның 1 статьясындагы 4 өлешенең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән шартлар керми.

*(2014 елның 18 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы, 2015 елның 9 апрелендәге 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

6. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 өлешенең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән хәлләрне раслау өчен кирәкле документлар, шулай ук әлеге статьяның 3 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары йә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына караган һәм дәүләт, муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнаша торган оешмалар эш итүендә булган документлар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында вәкаләтле орган тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алына.

*(2015 елның 9 апрелендәге 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

7. Документлар тапшырганда мөрәҗәгать итүчегә, аларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, шулай ук ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алыначак документларның исемлеген күрсәтеп, шушы документларның алынуына расписка бирелә.

8. Вәкаләтле орган ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылган һәм (яисә) алынган документларны тикшерү эшен оештыра һәм тапшыру бурычы мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән документлар тапшырылган көннән башлап 30 көннән дә соңга калмыйча шушы органга аларны исемлеккә кертү йә кертүдән баш тарту турында карар кабул итә.

*(2014 елның 18 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

9. Исемлеккә кертүдән баш тарту турындагы карар вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге очракта кабул ителә, әгәр:

1) ятим бала әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар категорияләренең берсенә дә кермәсә;

2) тапшыру бурычы мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән документлар тапшырылмаган яисә тулы күләмдә тапшырылмаган булса;



7. Шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы раслаган исемлек Федераль законның $16^{6}$ статьясындагы 22 өлеше нигезендә бастырып чыгарылырга тиеш.

*(2014 елның 3 мартындагы 13-ТРЗ номерлы, 2016 елның 26 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

8. Шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы тарафыннан ул раслаган исемлеккә гражданнарның шәхси составы һәм (яисә) торак урыннарының саны һәм (яисә) бүлмәләрнең саны турында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының расланган проект документациясе белән билгеләнгән торак йортларның гомуми мәйданы күләме чикләрендә түбәндәге очракларда үзгәрешләр кертелергә мөмкин:

*(2014 елның 3 мартындагы 13-ТРЗ номерлы, 2016 елның 26 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

1) үзен исемлектән төшереп калдыру турында гражданнан гариза алыну;

$1^{1}$) мондый исемлекләргә үзгәрешләр кертү шартнамә нигезендә төзелә торган эконом класслы торакның гомуми санын арттыруга китермәсә, гражданнан аны мондый исемлеккә кертү турында гариза алу;

*($1^{1}$ пункт 2016 елның 26 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

2) исемлеккә кертелгән гражданның вафат булуы яисә аны суд тарафыннан үлгән дип игълан итү;

3) әлеге өлешнең 1 яисә 2 пункты нигезендә мондый исемлектән төшереп калдырылган гражданны теркәү кенәгәсендә исәпкә алынган гаризасы булган башка граждан белән алмаштыру.

9. Исемлеккә үзгәрешләр Федераль законның $16^{6}$ статьясындагы 32 өлешенең 2 пунктында, $16^{16-1}$ статьясындагы 30 өлешенең 2 пунктында һәм $16^{16-2}$ статьясындагы 31 өлешенең 2 пунктында каралган мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Фондның рәсми сайтында урнаштырган көннән алып 12 ай чыкканчыга кадәр әлеге статьяда каралган тәртиптә кертелә.

*(2014 елның 3 мартындагы 13-ТРЗ номерлы, 2015 елның 16 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

10. Исемлектәге үзгәрешләр Федераль законның $16^{6}$ статьясындагы 25 өлеше нигезендә бастырып чыгарылырга тиеш.

җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан, гражданнарның гаризаларын теркәүнең хронологик тәртибе сакланган килеш, бирелгән исемлекләр нигезендә муниципаль берәмлекләрдә гаризалары исәпкә алынган гражданнар арасыннан төзелә. Берничә муниципаль берәмлектә гаризалары исәпкә алынган граждан исемлеккә теркәлү датасы элгәрәк булган гаризасы буенча кертелә.

*(2014 елның 3 мартындагы 13-ТРЗ номерлы, 2015 елның 1 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

4. Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә билгеләнгән шартларда эконом классны торак сатып алуга ризалык биргән гражданнарның гомуми саны шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган торак йортлар проект документациясе нигезендә Фондның җир кишәрлегендә төзелергә тиеш эконом классны торакта торак урыннарының гомуми саныннан артып китсә, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы гражданнарны исемлеккә хронологик тәртиптә гариза бирү тәртибе буенча түбәндәге чират белән кертә:

1) беренче чиратта исемлеккә яшәү өчен яраксыз дип билгеләнгән тәртиптә танылган торак урында йә билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип танылган күпфатирлы йорттагы торак урында яшәүче гражданнар, били торган торак урынның зурлыгына карамастан, кертеләләр;

2) икенче чиратта исемлеккә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә торучы гражданнар кертелә;

3) өченче чиратта исемлеккә өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләдә ата-ана булып торучы гражданнар кертелә.

5. Бер кешегә исәпләгәндә кереме алты яшәү минимумыннан артмаган һәм әлеге статьяның 4 өлешендәге 1 – 3 пунктларында каралган чиратлылык нигезендә категорияләргә кертелгән гражданнар исемлеккә беренче чиратта кертелү хокукына ия.

6. Фондның эконом классны торак төзү өчен түләүсез вакытлыча файдалану яисә аренда шартнамәсе, эконом классны торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен аренда шартнамәсе буенча тапшырылган җир кишәрлеге урнашкан территориядәге шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы исемлекне раслый һәм күрсәтелгән исемлекне Фондның җир кишәрлегендә аукционда җиңүче тарафыннан төзелергә тиешле торак йортлар төзелешенә рөхсәт бирү көненнән дә соңга калмыйча аукционда җиңүчегә җибәрә.

*(2014 елның 3 мартындагы 13-ТРЗ номерлы, 2015 елның 1 июлендәге 44-ТРЗ номерлы, 2016 елның 26 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*



3) тиешле документ мөрәҗәгать итүченең үз инициативасы белән тапшырылмаган булса, дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының йә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына караган оешманың ведомствоара гарызнамәгә җавабында соратып алына торган документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы таныкланса, моңа соратып алына торган мондый документның яисә мәгълүматның шушы органнар яисә оешмалар эш итүендә булмавы тиешле гражданнарның исемлеккә кертелү хокукын раслый торган очраклары керми;

4) тапшырылган документларда ятим бала турында дөрес булмаган белешмәләр булса.

10. Ятим баланы исемлеккә кертүдән баш тарту, исемлеккә кертүдән баш тарту өчен нигез булып хезмәт итүче шартларны бетергәннән соң, аны исемлеккә кертү турындагы гариза белән вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итү өчен тоткарлык була алмый.

11. Вәкаләтле орган ятим баланы исемлеккә кертү йә исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар кабул иткән көннән башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле документларны тапшырган гражданга ятим баланы исемлеккә кертү йә исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар кабул итүне раслый торган документ, аңа моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлеге булу йә булмау турындагы бәяләмәне өстәп, җибәрә.

12. Ятим балаларны исемлеккә кертү йә исемлеккә кертүдән баш тарту хакында карарга законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

*(2014 елның 18 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

### 2[1] статья. Ятим балаларның моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлекләре булмавын тану тәртибе

1. Вәкаләтле орган ятим балаларның моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлекләре булмавы шартларын билгеләү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – комиссия) төзи. Комиссиягә вәкаләтле орган җитәкчесе җитәкчелек итә.

2. Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы вәкаләтле орган җитәкчесе карары белән раслана.

3. Вәкаләтле орган әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән категориягә кертелгән ятим балага кагылышлы документларны алган очракта, комиссия, документларны тапшыру вазыйфасы йөкләнгән гариза бирүче тарафыннан документлар тапшырылганнан соң 14 көннән дә соңга калмыйча, әлеге органга ятим балаларның моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлекләренең булуы йә булмавы турында бәяләмә бирә.

4. Ятим балаларның моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлекләре булуы йә булмавы турында бәяләмәгә карата законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

*(статья 2014 елның 18 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

3 статья. **Ятим балаларга торак урыннары бирү тәртибе**

1. Торак урыннары әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарга 18 яшькә җиткәндә, шулай ук балигъ булганчы тулысынча хокукка сәләт алган очракта йә әлеге затларның мәгариф оешмаларында, медицина оешмаларында, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларында булу срогы алар 18 яшькә җиткәнче тәмамланганда бирелә.

*(2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Ятим бала 18 яшькә җитәргә йә аның мәгариф оешмасында, медицина оешмасында, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмасында булу срогы тәмамланырга бер ел калгач, законлы вәкил ятим баланы торак урыны белән тәэмин итү турындагы үтенечнамә белән вәкаләтле органга мөрәҗәгать итә. Элек тапшырылган документлардагы белешмәләр үзгәртелгәндә, законлы вәкил әлеге белешмәләрне үзгәртүләр турында үтенечнамәдә хәбәр итә.

*(2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Бирелгән үтенечнамәләр нигезендә вәкаләтле орган махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын алучы ятим балалар реестрын төзи, ятим баланы реестрга кертү турында законлы вәкилләргә 10 көн эчендә хәбәр ителә.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән хәлләр барлыкка килгән көннән 30 көн эчендә ятим балалар махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсе буенча торак урыны бирелү турында вәкаләтле органга гариза бирә.

5. Гариза биргән көннән 15 көннән дә соңга калмыйча вәкаләтле орган торак урыны бирү турында карар кабул итә һәм махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен биш ел срокка төзи.

Вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча һәм «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган оешма (коммерциячел булмаган республика оешмасы) белән килешү нигезендә соңгысына вәкаләтле орган исеменнән ятим балаларга торак урыннарын фактта бирү һәм алар белән югарыда күрсәтелгән шартнамәләр төзү гамәлләрен башкаруны йөкләргә мөмкин.

*(икенче абзац 2013 елның 28 октябрендәге 84-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*



7. Граждан, баш тарту өчен нигезләр бетерелгәннән соң, җирле үзидарәнең вәкаләтле органына гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

8. Гражданнарның исәпкә алынган гаризалары турындагы язмалар исемлектә теркәү кенәгәсе нигезендә хронологик тәртиптә урнаштырыла.

6 статья. **Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә билгеләнгән шартларда эконом класслы торак сатып алуга ризалык биргән гражданнар исемлекләрен төзү һәм исемлекләргә үзгәрешләр кертү кагыйдәләре**

1. Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә билгеләнгән шартларда эконом класслы торак сатып алуга ризалык биргән гражданнарның исемлеген төзү максатларында җирле үзидарәнең вәкаләтле органы эконом классы торак төзелеше өчен Фондның җир кишәрлекләрен түләүсез вакытлыча файдалану яисә аренда шартнамәсе, эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен Фондның җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсе төзегән датадан биш эш көне дәвамында, мондый шартнамәнең нәтиҗәләре турындагы беркетмәдәге белешмәләрне, шулай ук шартнамә төзүгә гражданның ризалыгын җибәрү срогын күрсәтеп, аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмати хәбәрне рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгара һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыра.

*(2014 елның 3 мартындагы 13-ТРЗ номерлы, 2015 елның 1 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

2. Исемлекне төзү һәм раслау максатларында Фондның эконом классы торак төзү өчен түләүсез вакытлыча файдалану яисә аренда шартнамәсе, эконом классы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен аренда шартнамәсе буенча тапшырылган җир кишәрлеге урнашкан территориядәге муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы муниципаль берәмлекләрдән шартнамә төзүгә гражданнарның ризалыгы белән бергә гражданнарның исәпкә алынган гаризаларының әлеге Законның 5 статьясы нигезендә төзелгән исемлеген соратып ала.

*(2014 елның 3 мартындагы 13-ТРЗ номерлы, 2015 елның 1 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

3. Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә билгеләнгән шартларда эконом классы торак сатып алуга ризалык биргән гражданнар исемлеге Фондның эконом классы торак төзү өчен түләүсез вакытлыча файдалану яисә аренда шартнамәсе, эконом классы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен аренда шартнамәсе буенча тапшырылган җир кишәрлеге урнашкан территориядәге муниципаль берәмлек

исемлектә күрсәтелгән затлар категорияләренә кертү өчен нигезләр, шулай ук исемлеккә гражданнарны кертү өчен исемлектә каралган нигезләр тикшерелә.

2. Гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча җирле үзидарәнең вәкаләтле органы гаризаны кабул итеп алган көннән соң 10 эш көне эчендә гражданны исемлеккә кертү өчен аның гаризасын исәпкә алу турында яки мондый исәпкә алудан баш тарту турында карар кабул итә.

3. Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы мөрәҗәгать итүчегә гаризаны исәпкә алудан түбәндәге нигезләр буенча баш тарта:

1) граждан исемлектә күрсәтелгән гражданнарның бер категориясенә дә туры килмәсә;

2) гражданны исемлекләргә кертү өчен исемлектә каралган нигезләр булмаса;

3) мөрәҗәгать итүче бирергә тиешле документлар бирелмәсә яисә тулы күләмдә бирелмәсә;

4) дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яки дәүләт хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы оешманың ведомствоара гарызнамәгә җавабы сорап алына торган документның һәм (яисә) мәгълүматның юклыгын дәлилләсә, әгәр тиешле документны мөрәҗәгать итүче үз теләге белән бирмәсә, моңа сорап алына торган әлеге документның яисә мәгълүматның шундый органнар яисә оешмалар карамагында булмавы тиешле гражданнарның исемлеккә кертү хокукын раслаган очраклар керми;

5) граждан һәм (яисә) аның гаилә әгъзалары турында яки исемлекләргә кертү нигезләре турында дөрес булмаган белешмәләр тапшырылса.

4. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы гражданга кабул ителгән карар турында һәм, гражданның гаризасын исәпкә алу турында карар кабул ителгән очракта, мәгълүмати хәбәрнамәдә күрсәтелгән срокта шартнамә төзүгә гражданның ризалыгын бирү зарурлыгы турында язма хәбәрнамә җибәрә.

5. Гражданның ризалыгы шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йортларның һәм (яисә) блоклы төзелә торган торак йортларның, индивидуаль торак йортларның (алга таба – торак йортлар) проект документациясе расланганнан да иртәрәк булмаган вакытта, граждан шартнамә төзеячәк торак урынны бердәйләштерү мөмкинлеге бирә торган индивидуаль билгеләнгән характеристикаларны күрсәтеп, рәсмиләштерелә.

*(2014 елның 3 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6. Исемлеккә кертү өчен граждан гаризасын исәпкә алудан баш тартуга карата мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.



6. Торак урыны бирү мизгеленә әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган ятим балалар махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын алучы ятим балалар реестрыннан төшереп калдырылырга тиеш, бу хакта аларга вәкаләтле орган 10 көн эчендә хәбәр итә.

7. Ятим балалар өчен махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәләре буенча торак урыннары биләүче ятим балалар тарафыннан торак урыннары һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен билгеләнгән тарифлар буенча башкарыла.

8. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсе буенча торак урыннарын биләүче һәм «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә аз керемлеләр дип танылган ятим балалар торак урыныннан файдаланган өчен түләү (яллау өчен түләү) кертүдән азат ителә.

9. Ятим балалар өчен махсуслаштырылган торак фондында буша- ган торак урыннары булмаган очракта, вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда ятим балаларның уңайлы торак урыннарында вакытлыча яшәвен тәэмин итә.

10. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсе өзелгәндә яисә туктатып торылганда, социаль яллау шартнамәсе төзелү очракларыннан гайре, торак урыны әлеге Закон нигезендә торак урыны белән тәэмин ителүгә мохтаҗ бүтән затка бирелә.

### 4 статья. **Ятим балалар өчен торак урыннарының сакланышын тәэмин итү**

1. Вәкаләтле орган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән кызыксынучы органнары белән хезмәттәшлектә билгеләнгән компетенция кысаларында социаль яллау шартнамәләре буенча яллаучылары яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре ятим балалар булган, бирелгән торак урыннарыннан файдалануны һәм (яисә) эш итүне, шушы торак урыннарының тиешле санитария хәлен һәм техник торышын тәэмин итүне түбәндәге максатларда тикшереп тора:

1) торак урынын алмаштыру яисә читләштерү буенча законсыз алыш-биреш килешүләре башкаруны булдырмый калу;

2) торак урынында шуңа законлы нигезләре булмаган затларның яшәвен булдырмый калу;

3) торак урынын билгеләнеше буенча файдалануны тәэмин итү, тиешле халәттә тоту;

4) санитар-техник һәм бүтән төрле җайланмаларның сакланышын тәэмин итү;

5) янгын куркынычсызлыгы таләпләрен, санитария-гигиена һәм экологик таләпләрне үтәү;

6) торак урынында аны бозуга китерерлек эшләр яисә башка гамәлләр башкаруны булдырмый калу;

7) торак урынын билгеләнгән тәртипне бозып үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны булдырмый калу.

2. Вәкаләтле орган, торак урыннарының сакланышын һәм алардан файдалануны бозулар ачыкланганда, торак урынын карап чыгу актын төзи һәм аларны бетерү буенча кичекмәстән чаралар күрә.

**5 статья. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен яңа срокка төзү яисә бирелгән торак урынына карата социаль яллау шартнамәсен төзү тәртибе**

1. Вәкаләтле орган махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы тәмамланганга кадәр өч ай алдан әлеге шартнамә буенча яллаучының тормыш шартларын тикшерә, авыр тормыш хәлләрен җиңеп чыгуда ятим балаларга ярдәм итү зарурлыгын таныклый торган хәлләрнең булуын йә булмавын билгеләү максатларында кирәкле белешмәләрне һәм документларны (яллаучының тормыш шартларын карап чыгу актларын, гаилә составы һәм торак урынында теркәлгән затлар турында, яллаучының керемнәре турында, яллаучының, аның гаилә әгъзаларының авыруы, инвалидлыгы булу-булмау турында яшәү урыныннан документларны, яллаучыга карата хокук саклау органнарының чыгарылган актларын, яллаучының җәза үтәвен (булган очракта) раслый торган документларны) соратып ала.

2. Тикшерү нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган авыр тормыш хәлләрен җиңеп чыгуда ятим балаларга ярдәм итү зарурлыгын таныклый торган хәлләр булу йә булмау турында бәяләмә чыгара.

3. Вәкаләтле органның бәяләмәсендә махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен яңа срокка төзүнең яисә яллаучы били торган торак урынын социаль яллау шартнамәсен төзүнең нигезлелеге хакындагы нәтиҗә булырга тиеш.

4. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы тәмамланырга 30 көн кала вәкаләтле орган авыр тормыш хәлләрен җиңеп чыгуда ятим балаларга ярдәм итү зарурлыгын раслый торган хәлләр булу турындагы бәяләмә нигезендә махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен яңа срокка бер мәртәбә төзү турында карар кабул итә, бу хакта карар кабул ителгән көннән 10 көн эчендә ятим балага хәбәр ителә.

5. Авыр тормыш хәлләрен җиңеп чыгуда ятим балаларга ярдәм итү зарурлыгын раслый торган хәлләр булмау турындагы бәяләмә нигезендә вәкаләтле орган махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы тәмамланырга 30 көннән дә соңга кал-



**4 статья. Фондның җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торак сатып алу хокукына ия гражданнарның гаризалар бирү һәм аларны исәпкә алу тәртибе**

1. Исемлекләргә кертү турындагы гаризаларны (алга таба – гаризалар) бирү хокукына Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән яисә төп эш (хезмәт) урыны булган, исемлеккә кертелгән гражданнар категорияләренә караган Россия Федерациясе гражданнары ия була.

2. Гариза граждан тарафыннан шәхсән яисә вәкиле аша турыдантуры йә дәүләт хезмәт күрсәтүләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең региональ порталыннан файдаланып электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күп функцияле үзәге аша яисә кәгазьдә, исемлеккә кертелә торган Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган белешмәләр составы белән каралган документларны кушып, яшәү урыны яисә төп эш (хезмәт) урыны буенча җирле үзидарәнең вәкаләтле органына бирелә.

3. Гаризаны вәкил аша тапшырган очракта, гаризага Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә кушып бирелергә тиеш.

4. Граждан, документлар дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары карамагында һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмаларда, шулай ук Фондта булса, әлеге статьяның 2 өлешендә каралган документларны гаризага кушып бирмәскә хокуклы. Бу очракта документлар җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан ведомствоара йә бүтән рәвешләрдәге хезмәттәшлек тәртибендә мөстәкыйль соратып алына.

5. Гаризада гражданның үз гаризасындагы шәхси белешмәләрне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә эшкәртүгә ризалыгы күрсәтелә.

6. Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) мөрәҗәгать итү көнендә гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны алу турында, шушы документларның исемлеген һәм аларны алу датасын, шулай ук ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алыначак документлар исемлеген күрсәтеп, расписка бирелә.

7. Әлеге статья нигезендә кергән барлык гаризалар теркәү кенәгәсендә хронологик тәртиптә (гариза бирү датасы һәм вакыты буенча) теркәлә.

**5 статья. Фондның җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торак сатып алу хокукына ия гражданнар гаризаларын карау тәртибе**

1. Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан гаризалар һәм аларга кушып бирелгән документлар каралганда, гражданнарны

3 статья. **Исемлекләр төзү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. Шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы:

*(2016 елның 26 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

1) исемлекләрне раслый һәм Федераль законда каралган очракларда аларга үзгәрешләр кертә;

2) исемлекләр, шулай ук аларга үзгәрешләр басылып чыгарга тиешле рәсми массакүләм мәгълүмат чараларын билгели;

3) исемлекләрне һәм аларга үзгәрешләрне шушы исемлекләр расланган һәм аларга үзгәрешләр кертелгән датадан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә.

2. Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы:

1) Федераль законның $16^6$ статьясындагы 35 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләре һәм аларны исемлекләргә кертү нигезләре исемлегенә (алга таба – исемлек) кертелгән гражданнар турында мондый гражданнарны исемлекләргә кертү өчен нигезләр булуны билгеләү максатында белешмәләр җыюны гамәлгә ашыра һәм муниципаль берәмлекнең эконом класслы торакка кертү шартларына туры килерлек торак урыннарының минималь гомуми күләменә (шул исәптән тиешле бүлмәләр саны белән кирәкле торак урыннарының минималь гомуми санына һәм торак урыннарының гомуми мәйданының минималь күләменә) ихтыяҗын билгели;

2) теркәү кенәгәсен һәм гражданнарның исәпкә алынган гаризалары исемлеген алып бара, аларны алып бару тәртибе нигезендә шулардан өземтәләр бирә;

3) булган очракта, вәкаләтле органга түбәндәге тәкъдимнәрне җибәрә:

а) муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан торак пунктлардагы эконом класслы торакка кертү шартларына туры килерлек торак урыннарының минималь гомуми күләменә ихтыяҗ турында (торак төзелешенең күз алдында тотылучы төрен, тиешле бүлмәләр саны белән кирәкле торак урыннарының минималь гомуми санын һәм торак урыннарының гомуми мәйданының минималь күләмен күрсәтеп);

б) муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан, эконом класслы торак төзү өчен аукционнар үткәрелергә мөмкин федераль милектәге яисә дәүләт милке итеп алынмаган җир кишәрлекләре турында;

*(2015 елның 16 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган рәвештә исемлекләр төзи, шулай ук мондый исемлекләргә үзгәрешләр әзерли.



мыйча махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен өзү һәм шушы торак урынын социаль яллау шартнамәсе төзү турында карар кабул итә, бу хакта карар кабул ителгән көннән 10 көн эчендә ятим балага хәбәр ителә.

6. Әлеге статьяның 4 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән карарларга карата суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

7. Вәкаләтле орган карар кабул ителгән көннән 30 көннән дә соңга калмыйча махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен өзә һәм әлеге торак урынын социаль яллау шартнамәсен төзи йә махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен биш еллык яңа срокка төзи.

6 статья. **«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 19 июнь, 25 июль), 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучы яисә социаль яллау шартнамәсе буенча торак урынын яллаучының гаилә әгъзалары булмаган йә торак урыннары милекчеләре булмаган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, шулай ук социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучы яисә социаль яллау шартнамәсе буенча торак урыннарын яллаучының гаилә әгъзалары булган йә торак урыннары милекчеләре булган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, әгәр аларның элек били торган торак урыннарында яшәүләре мөмкин түгел дип танылса, махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тәэмин ителергә тиеш.

Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга мөлкәткә һәм торак урынына хокукларның өстәмә гарантияләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

7 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның гамәли көче, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар үзләренең торак урыннары белән тәэмин ителү хокукын 2013 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлгә ашырмаган очракта, «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 29 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән 30 көн эчендә әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 8-ТРЗ

1) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктында каралган тәкъдимнәрне (алга таба – җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тәкъдимнәре) әзерләү турындагы гарызнамәләрне җирле үзидарә органнарына җибәрә, аларны җыюны һәм гомумиләштерүне тәэмин итә;

*(2016 елның 26 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2) Федераль законның 11 статьясындагы $6^8$ һәм $6^9$ өлешләре нигезендә, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тәкъдимнәренә таянып, эконом класслы торак төзелешенә ихтыяҗ булу турында үтенечнамә (алга таба – үтенечнамә) әзерли һәм Фонд тарафыннан алга таба Федераль законның $16^6$ – $16^{6-2}$ статьяларында каралган аукционнар үткәрү максатларында Фондка җибәрә;

*(2015 елның 16 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3) җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тәкъдимнәре составында муниципаль берәмлекләр территориясендә эконом класслы торак төзү өчен файдаланырга мөмкин булган федераль милектәге җир кишәрлекләре, дәүләт милке итеп алынмаган җир кишәрлекләре, шул исәптән аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары белән, булу турында белешмәләр алган очракта, бер үк вакытта Федераль законның 11 статьясында каралган исемлекләрне үтенечнамәләр белән бергә җибәрүне тәэмин итә;

*(2015 елның 16 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4) әлеге Законда каралган мәгълүмати хәбәрләрне рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә;

5) Федераль законның $16^6$, $16^{6-1}$ статьялары нигезендә Фонд федераль милектәге җир кишәрлекләрен, дәүләт милке итеп алынмаган җир кишәрлекләрен яисә Фондның җир кишәрлекләрен эконом класслы торак төзү өчен мондый җир кишәрлекләреннән түләүсез вакытлыча файдалану яисә аларны арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукционнар, шулай ук эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен аренда шартнамәләрен төзү хокукына аукционнар (алга таба – аукцион) уздыру максатларында сайлап алу буенча чаралар үткәргәндә Федераль законда каралган тәртиптә Фонд белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

*(2014 елның 3 мартындагы 13-ТРЗ номерлы, 2015 елның 16 мартындагы 16-ТРЗ номерлы, 2015 елның 1 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

6) әлеге Законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне дә башкара.

сына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала.

*(2015 елның 1 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2 статья. **Исемлекләр төзү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) әлеге статьяның 2 өлешендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба – вәкаләтле орган) билгели;

2) гражданнарның гаризаларын теркәү кенәгәсе (алга таба – теркәү кенәгәсе), шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә исемлекләргә кертү хокукына ия гражданнарның гаризалары исемлеге (алга таба – гражданнарның исәпкә алынган гаризалары исемлеге) рәвешен һәм алып бару тәртибен билгели;

3) исемлеккә кертү турында граждан гаризасының рәвешен билгели;

4) гражданның өлешле төзелештә катнашу шартнамәсен яисә сату-алу шартнамәсен төзүгә язма ризалыгы (алга таба – шартнамә төзүгә гражданның ризалыгы) рәвешен билгели;

5) әлеге Законда каралган мәгълүмати хәбәрләрне бастырып чыгарырга тиешле рәсми массакүләм мәгълүмат чараларын билгели;

6) «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның эконом класслы торак сатып алу хокукына ия категорияләре исемлеген раслый, җирле үзидарә органнары тарафыннан мөрәҗәгать итүче гражданнарның эконом класслы торак сатып алу хокукына ия гражданнарның билгеләнгән категорияләренә туры килүен тикшерү тәртибен, җирле үзидарә органнары тарафыннан эконом класслы торак сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү һәм раслау тәртибен, аларга үзгәрешләр кертү тәртибен, шулай ук мондый исемлеккә кертелгән гражданнарның Татарстан Республикасы буенча җыелма реестрын алып бару тәртибен һәм күрсәтелгән реестрда булган белешмәләрне Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә эконом класслы торак төзү максатларында территорияләрне үзләштерү турында шартнамәләр яисә эконом класслы торак төзү максатларында территорияләрне комплекслы үзләштерү турында шартнамәләр төзегән юридик затларга бирү тәртибен билгели.

*(6 пункт 2015 елның 16 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

2. Вәкаләтле орган:



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Россия Федерациясенең Торак кодексы нигезендә Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча (алга таба – наем шартнамәсе) гражданнарга торак урыннар бирүнең аерым мәсьәләләрен җайга сала, гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен ачыклау һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләренең хакын билгеләү тәртибен нигезли һәм гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү тәртибен ачыклый.

2 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Наем шартнамәләре буенча торак урыннар Россия Федерациясенең Торак кодексында билгеләнгән нигезләргә ярашлы рәвештә торак урыннарга мохтаҗлар дип танылган гражданнарга һәм башка федераль законда, Россия Федерациясе Президенты указында, Татарстан Республикасы законында яисә җирле үзидарә органының вәкиллекле органы актында билгеләнгән нигезләргә ярашлы рәвештә наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип танылган гражданнарга түбәндәге очракларда бирелергә мөмкин:

1) гражданның һәм аның белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының кереме һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләренең хакы әлеге Законның 5 статьясы нигезендә билгеләнә торган максималь күләмнән артып китмәсә;

2) граждан «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә аз керемле дип танылмаган булса һәм аз керемле дип тану өчен нигезләргә ия булмаса.

3 статья. **Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен, шул исәптән әлеге исәпкә кую, исәпкә куюдан баш тарту, аннан төшереп калдыру тәртибен билгеләү;

2) наемга бирүчеләр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, әлеге органнар тарафыннан хокук бирелгән оешмалар яисә Россия Федерациясе Торак кодексының 91[2] статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән һәм мондый органнар тарафыннан төзелгән оешмалар булган очракларда, гражданнарның наем шартнамәсе буенча торак урын бирү турында гаризаларын наемга бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибен билгеләү;

3) социаль файдаланудагы наем йортларын һәм аларны төзү өчен бирелгән яисә билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу тәртибен билгеләү;

4) барлык урыннары Татарстан Республикасы милкендә булган наем йортлары белән һәм наем йортлары булган, Татарстан Республикасы милкендә саналган торак йортлар белән идарә итү тәртибен раслау;

5) әгәр наемга бирүчеләр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, әлеге органнар тарафыннан хокук бирелгән оешмалар яисә Россия Федерациясе Торак кодексының 91[2] статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән һәм мондый органнар тарафыннан төзелгән оешмалар булса, торак урынны наем шартнамәсе буенча наемга алган өчен түләү күләмен билгеләү;

6) торак урынны наем шартнамәсе буенча наемга алган өчен түләүнең максималь күләмен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре өчен дифференциация ясап билгеләү;

7) Татарстан Республикасы милкендәге торак урыннарны наем шартнамәләре буенча наемга бирергә хокуклы оешмаларның мондый шартнамәләрне төзүгә һәм үтәүгә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү-үтәмәвен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

8) Россия Федерациясе Торак кодексында һәм әлеге Законда каралган башка төрле вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә җирле үзидарә органнарының вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында**

*(исеме 2015 елның 16 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

*(2014 елның 3 мартындагы 13-ТРЗ номерлы,
2015 елның 16 мартындагы 16-ТРЗ номерлы,
2015 елның 1 июлендәге 44-ТРЗ номерлы,
2016 елның 26 мартындагы 21-ТРЗ номерлы
Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге Закон «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү федераль фондының (алга таба – Фонд) эконом класслы торак төзү өчен, шул исәптән мондый торак төзү максатларында комплекслы үзләштерү өчен, түләүсез вакытлыча файдалануга яисә арендага (алга таба – эконом класслы торак төзү өчен түләүсез вакытлыча файдалану яисә аренда), шулай ук эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен, шул исәптән эконом класслы торакны һәм башка торак төзелешен минималь таләп ителә торган күләмдә төзү максатларында комплекслы үзләштерү өчен арендага (алга таба – эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен аренда) тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торакка кертү шартларына туры килә торган күпфатирлы йортларда һәм (яисә) блоклы төзелә торган торак йортларда торак урыннар, индивидуаль торак йортлар (алга таба – эконом класслы торак) сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү кагыйдәләрен һәм күрсәтелгән гражданнарны Фондның эконом класслы торак төзү өчен түләүсез вакытлыча файдалануга яисә арендага, шулай ук эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен арендага тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торак сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләренә (алга таба – исемлек) кертү тәртибен, аерым алганда, чиратлылыгын билгели, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодек-

йортларга хезмәт күрсәтү стандартларын, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге оешмаларның башка стандартларын эшләргә һәм расларга мөмкин.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары үз вәкаләтләре чикләрендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә үз-үзен җайга салуның үсешенә булышлык күрсәтәләр.

11 статья. **Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык**

Әлеге Законны бозу законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

12 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2011 елның 10 октябре
№ 72-ТРЗ

белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләренең хакын билгеләү;

2) гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзалары кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү;

3) җирле үзидарә органнары, әлеге органнар тарафыннан хокук бирелгән оешмалар яисә Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{2}$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән һәм мондый органнар тарафыннан төзелгән оешмалар наемга бирүчеләр булса, гражданнарның наем шартнамәсе буенча торак урын бирү турында гаризаларын наемга бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибен билгеләү;

4) гражданнарның наем шартнамәсе буенча торак урын бирү турында гаризаларын исәпкә алу тәртибен Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{14}$ статьясындагы 5 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән наемга бирүчеләр белән килештерү кагыйдәләрен билгеләү;

5) наем шартнамәләре буенча торак урын бирелүгә мохтаҗ гражданнарның исәбен алып бару;

6) наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынның, бер кешегә исәпләгәндә, гомуми мәйданы күләмен билгеләү (торак урынның гомуми мәйданы күләме Россия Федерациясе Торак кодексының 58 статьясындагы нигезләмәләрне исәпкә алган торак урын бирү нормасыннан кимрәк була алмый);

7) барлык урыннары муниципаль берәмлек милкендә булган һәм, наем йортлары булып, муниципаль берәмлек милкендәге торак йортлар булган наем йортлары белән идарә итүнең тәртибен билгеләү;

8) социаль файдаланудагы наем йортларын һәм җир турындагы законнар нигезендә мондый йортлар төзү өчен бирелгән яисә билгеләнгән җир кишәрлекләрен социаль файдаланудагы наем йортларының муниципаль реестрында исәпкә алуны гамәлгә ашыру;

9) җирле үзидарә органнары, әлеге органнар тарафыннан хокук бирелгән оешмалар яисә Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{2}$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән һәм мондый органнар тарафыннан төзелгән оешмалар наемга бирүчеләр булса, торак урынны наем шартнамәсе буенча наемга алган өчен түләү күләмен билгеләү;

10) Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{14}$ статьясындагы 5 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән наемга бирүчеләргә торак урынны наем шартнамәсе буенча наемга алган өчен түләү күләмен килештерү;

11) муниципаль берәмлек милкендәге торак урыннарны наем шартнамәләре буенча наемга бирергә хокуклы оешмаларның мондый шартнамәләрне төзүгә һәм үтәүгә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү-үтәмәвен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

12) наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар исәбенә куелган гражданнарга наем шартнамәләре буенча бирелә алган

торак урыннарның саны турында хәбәр итүнең тәртибенә, рәвешенә һәм срокларына карата (шул исәптән белешмәләр исемлегенә, аларны бирү ешлыгына, рәвешенә һәм урынына, мәгълүмат урнаштыру ешлыгына, рәвешенә һәм урынына карата) таләпләрне билгеләү;

13) Россия Федерациясе Торак кодексында һәм әлеге Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү тәртибе**

1. Һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләме әлеге Законга кушымта итеп бирелгән Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы нигезендә ачыклана.

2. Һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләме мондый гаилә әгъзаларына һәм мондый гражданга тиешле муниципаль берәмлек территориясендә үз акчаларына, торак урын сатып алуга кредит яисә заем исәбеннән торак урынны милеккә сатып алырга мөмкинлек бирә торган күләмнән артып китә алмый.

3. Һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан керееменең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен яңадан карау елга бер тапкыр башкарыла.

6 статья. **Һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан керееменең күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган керем төрләре**

Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан керееменең күләмен исәпләгәндә һәр гаилә әгъзасы яисә ялгыз яшәүче граждан тарафыннан акчалата һәм әйберләтә алынган барлык керем төрләре дә исәпкә алына, шул исәптән:

1) законнар нигезендә уртача хезмәт хакын хисаплаганда исәпкә алына торган, хезмәт өчен түләү системасында каралган барлык түләүләр;

2) хезмәт законнарында каралган очракларда сакланып кала торган уртача хезмәт хакы;

3) дәүләт яисә җәмәгать бурычларын башкару вакытында дәүләт органы яисә җәмәгать берләшмәсе тарафыннан түләнә торган компенсация;



4. Идарәче оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр һәм башка акчалар бирү шартлары буларак, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан түбәндәгеләр дә күздә тотылырга мөмкин:

1) идарәче оешма эшчәнлегенә даими аудит үткәрү;

2) идарәче оешма тарафыннан торак һәм торак булмаган урыннарның гомуми мәйданы (гомуми файдаланудагы урыннардан тыш) 100 мең квадрат метрдан артмаган күпфатирлы йорт (күпфатирлы йортлар) белән идарә итүне гамәлгә ашыру;

3) түләү документында билгеләнгән хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең төренә бәйле рәвештә, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне банклар счетларында туплау;

4) торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдән алына торган акчаларны түләү документында билгеләнгән хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр исемлеге нигезендә тоту;

5) билгеле бер эшләр башкарган һәм хезмәтләр күрсәткән өчен түләү буларак алына торган акчаларны бары тик әлеге эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне башкаруга гына юнәлдерү;

6) планлаштырыла торган эшләр исемлеген һәм күләмен күрсәтеп, күпфатирлы йорт белән идарә итүгә бәйле эшләр үткәрү планы һәм агымдагы елга смета булу;

7) коммуналь хезмәтләр өчен исәп-хисапларны гражданнар һәм ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар арасында турыдан-туры гамәлгә ашыру.

5. Күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләренең гомуми җыелышында торак урын өчен түләүдән идарәче оешма тарафыннан алынган акчаларны әлеге статьяның 4 өлешендәге 5 пункты таләпләрен үтәмичә тоту турында карар кабул ителергә мөмкин. Тиешле карар акчаларны шулай тотуның һәр очрагы өчен аерым кабул ителә.

10 статья. **Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә үз-үзен җайга салу**

1. Идарәче оешмалар федераль законнар нигезендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә үз-үзен җайга салучы оешмалар төзергә хокуклы, алар үз-үзен җайга салучы оешмаларның һәм аларның әгъзаларының алар күрсәтә торган торак-коммуналь хезмәтләрдән файдаланучылар, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен эшкуарлык яисә һөнәри эшчәнлек субъектларын берләштерәләр.

2. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә үз-үзен җайга салучы оешмалар техник җайга салу турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән максатларда һәм тәртиптә күпфатирлы

5) коммуналь хезмәтләр күрсәтү һәм торак фондына хезмәт күрсәткән өчен түләү күләменең нигезләнгән булуын;

6) күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеге стандартларын һәм кагыйдәләрен, мәгълүматны ачу стандартын үтәүне;

7) конкурслар процедураларының гавами булуын;

8) күпфатирлы йортлар белән идарә итү шартнамәсен һәм күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләренең гомуми җыелышларының үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарларын, шул исәптән күпфатирлы йорт урнашкан җир кишәрлегеннән файдалану һәм күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең уртак мөлкәтеннән файдалану мәсьәләләре буенча да, үтәүне.

2. Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышында идарәче оешманы сайлап алганда мондый йорттагы һәрбер урын милекчесе белән федераль законнарда һәм шушы гомуми җыелыш карарында билгеләнгән шартларда идарә итү шартнамәсе төзелә.

Әлеге шартлар ресурслар белән тәэмин итүче һәм коммуналь предприятиеләр белән шартнамәләр төзегәндә идарәче оешманың торак һәм коммуналь хезмәтләрдән файдаланучыларның хокукларын яклау гарантияләрен тәэмин итү йөкләмәсен дә күздә тотарга мөмкин, шул исәптән ресурслар белән тәэмин итүче һәм коммуналь предприятиеләр ягыннан шартнамәләрне бозган очракта да.

**9 статья. Идарәче оешмаларга бюджет ассигнованиеләре бирү үзенчәлекләре**

1. Идарәче оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет законнары белән билгеләнгән рәвешләрдәге бюджет ассигнованиеләре түбәндәгеләргә бирелергә мөмкин:

1) күпфатирлы торак йортларга капиталь ремонт ясауны финанслашуга;

2) муниципаль өлеш булган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне тотуны финанслашуга;

3) идарәче оешмаларның хезмәткәрләрен әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм аларның квалификациясен күтәрүгә;

4) гражданнарның торак хокукларын гамәлгә ашыруны һәм яклауны тәэмин итүгә бәйле бүтән максатларга.

2. Идарәче оешмаларга бюджет ассигнованиеләре чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда карала.

3. Бюджет ассигнованиеләрен күчерү идарәче оешмаларның конкурс нигезендә билгеләнә торган банктагы хисап счетларына билгеләнгән тәртиптә күчерелә. Конкурс шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.



4) эштән җибәрелгәндә түләнә торган эштән китү пособиесе, отставкага чыккандагы компенсация, оешма бетүгә, штатлар саны яисә хезмәткәрләр штаты кыскартылуга бәйле рәвештә эштән җибәрелгәндә эшкә урнашу чорына сакланып кала торган хезмәт хакы;

5) барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан, бюджеттан тыш дәүләт фондларыннан һәм башка чыганаклардан социаль түләүләр, аларга түбәндәгеләр керә:

а) пенсияләр, компенсация түләүләре (хезмәткә яраксыз гражданнарны тәрбияләүче хезмәткә яраклы эшләмәүче затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм пенсионерларны ай саен өстәмә матди тәэмин итү;

б) отставкага киткән судьяларны гомер буена ай саен тәэмин итү;

в) стипендияләр, шул исәптән студентларга дәүләт академия стипендиясе, студентларга дәүләт социаль стипендиясе, бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге бүлектә укучы аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендияләре, мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында каралган башка стипендияләр һәм акчалата түләүләр;

г) эшсезлек буенча пособие, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм башка түләүләр, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри әзерлек, яңадан әзерлек һәм квалификация күтәрү чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлыча эшләрдә катнашу чорында түләүләр, шулай ук 14 яшьтән алып 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарга аларның вакытлыча эшләрдә катнашу чорында түләүләр;

д) вакытлыча хезмәткә яраксыз булу буенча пособие, йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие, шулай ук йөклелекнең башлангыч срокларында медицина оешмаларында исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр түләнә торган пособие;

е) балага айлык пособие;

ж) яшь ярымга җиткәнче баланы карау буенча отпуск чорына айлык пособие һәм хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы һәм өч яшькә җиткәнче бала карау буенча отпуск ялындагы гражданнарга айлык компенсация түләүләре;

з) эшләмәскә мәҗбүр булган яисә белгечлек буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмау сәбәпле эшкә урнаша алмаган һәм билгеләнгән тәртиптә эшсезләр буларак танылган урыннарда ирләре белән яшәгән чорда, шулай ук, әгәр дә медицина оешмасы биргән бәяләмәдә балалары 18 яшькә җиткәнче икенче бер кешенең карап торуына мохтаҗ дип билгеләнгән булса, иренең хәрби хезмәт итү урынында яшәү шартларына бәйле рәвештә хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары балаларының сәламәтлеге торышы буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрнең хатыннарына айлык пособие;

и) аеруча ерак горнизоннардагы һәм җирлекләрдәге Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкчелек составы затларының эшләмәүче хатыннарына аларны хезмәткә урнаштыру мөмкинлеге булмаганда айлык компенсация түләве;

к) производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәргә бәйле авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү буенча айлык иминият түләүләре;

л) әлеге пунктта күрсәтелгән барлык түләү төрләренә карата арттырып түләүләр, өстәмә түләүләр һәм Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан билгеләнгән башка социаль түләүләр;

6) гаиләнең (аның аерым әгъзаларының) яисә ялгыз яшәүче гражданның милек хокукындагы мөлкәтеннән алынган керемнәр, аларга түбәндәгеләр керә:

а) күчемсез мөлкәтне (җир кишәрлекләрен, йортларны, фатирларны, дачаларны, гаражларны), транспорт һәм башка төрле механика чараларын, продуктларны эшкәртү һәм саклау чараларын сатудан һәм арендага (субарендага, наемга, өстәмә наемга) бирүдән алынган керемнәр;

б) шәхси ярдәмче хуҗалык уңышларын һәм продукцияләрен (күпьеллык утыртмалар, бакча продукциясе, продукция буларак һәм күрсәтү өчен үстерелгән хайваннар, кошлар, кыйммәтле мехлы җәнлекләр, умарта кортлары, балык) сатудан алынган керемнәр. Күрсәтелгән керемнәргә, җир кишәрлегеннән алынып, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан тарафыннан шәхси куллану өчен файдаланылган уңышлар һәм продукция керми;

7) гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның башка керемнәре, аларга түбәндәгеләр керә:

а) хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының җинаять-үтәтү учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясенең таможня органнары һәм хокук саклау хезмәтенең бүтән органнары хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән даими башкарыла торган өстәмә түләүләр һәм азык-төлек белән тәэмин ителү (азык-төлек паегына алмашка акчалата компенсация);

б) хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының җинаять-үтәтү учреждениеләреннән һәм органнарыннан, Россия Федерациясенең таможня органнарыннан, хокук саклау хезмәтенең бүтән органнарыннан эштән киткәндә бер тапкыр бирелә торган пособие;

в) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләр өчен түләү;



торган хезмәтләр һәм (яисә) башкарыла торган эшләр күләме, исемлеге һәм сыйфаты турындагы, күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләргә бәяләр (тарифлар) һәм шушы хезмәтләр өчен түләү күләмнәре турындагы, җирле үзидарә органнары вәкилләренең күпфатирлы йорт милекчеләренең еллык һәм чираттан тыш гомуми җыелышларында катнашуы турындагы мәгълүматны, шул исәптән торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасын кулланып бирергә тиеш.

*(2015 елның 9 апрелендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4. Җирле үзидарә органнары гражданнарга аларның гарызнамәләре буенча торак өлкәсендәге һәм коммуналь хезмәтләр өлкәсендәге муниципаль программалар турындагы, җирле үзидарә органнарының шушы өлкәләрдәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актлары турындагы, муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының торышы турындагы, әлеге объектларны эксплуатацияләүче затлар турындагы, коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларның җитештерү программалары турындагы һәм инвестиция программалары турындагы, мондый оешмаларның товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре сыйфатының билгеләнгән параметрларын үтәү турындагы, коммуналь хезмәтләрне башкаручыларның (коммуналь хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы затларның) коммуналь хезмәтләр өчен кирәкле ресурслар җитештерүне һәм реализацияләүне гамәлгә ашыручы затлар белән, шулай ук су бирүче затлар белән исәп-хисапларның торышы турындагы, кулланучыларның коммуналь хезмәтләр күрсәтүчеләр белән исәп-хисапларының торышы турындагы мәгълүматны, шул исәптән торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасын кулланып бирергә тиеш.

*(2015 елның 9 апрелендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

### 8 статья. **Гражданнарның торак хокукларының үтәлүен идарәче оешмалар тарафыннан тәэмин итү**

1. Идарәче оешмалар үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда законнар нигезендә түбәндәгеләрне тәэмин итәләр:

1) коммуналь хезмәтләр күрсәтү һәм торак фондына хезмәт күрсәтү буенча эшчәнлекнең законлылыгын;

2) коммуналь хезмәтләр күрсәтүдән һәм торак фондына хезмәт күрсәтүдән файдаланучылар хокуклары үтәлүне;

3) коммуналь хезмәтләр күрсәтүдән һәм торак фондына хезмәт күрсәтүдән файдаланучылар белән нәтиҗәле хезмәттәшлек булдыруны;

4) коммуналь хезмәтләр күрсәтүдән һәм торак фондына хезмәт күрсәтүдән файдаланучылар өчен хезмәтләр күрсәтүдән файдалануга тигез мөмкинлек тәэмин итүне;

7 статья. **Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан шартлар тудыру**

1. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өчен шартлар тудыру максатларында җирле үзидарә органнары түбәндәгеләрне гамәлгә ашыралар:

1) оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә, идарәче оешмалар эшчәнлеге өчен тигез шартлар тәэмин итәләр;

2) идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә йә торак кооперативларына яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау өчен бюджет акчалары бирә алалар;

3) күпфатирлы йортлар белән идарә итүче затларның квалификация дәрәҗәсен күтәрүгә һәм мондый эшчәнлекне башкару нияте булган затларны укытуны оештыруга ярдәм итәләр;

4) барлык урыннары да муниципаль берәмлек милкендә булган күпфатирлы йорт белән идарә итү тәртибен билгелиләр;

5) күпфатирлы йортлар белән идарә итүдә катнашалар, шул исәптән уртак мөлкәткә уртак милекчелек хокукындагы өлеше муниципаль милектә булган күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышларында катнашу өчен вәкилләр җибәрү юлы белән дә;

6) үз компетенциясе чикләрендә башка чараларны гамәлгә ашыралар.

2. Идарәче оешманың Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясындагы 2 өлешендә каралган йөкләмәләрне үтәмәве турында күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре, күпфатирлы йорт советы рәисе, торак милекчеләре ширкәте идарә органнары йә торак кооперативы идарә органнары яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы идарә органнары, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 8 өлешендә күрсәтелгән иҗтимагый берләшмәләр, коммерциясез башка оешмалар мөрәҗәгате нигезендә җирле үзидарә органнары биш көн эчендә идарәче оешма эшчәнлеген планнан тыш тикшерү үткәрә. Әгәр әлеге тикшерү нәтиҗәләре буенча идарәче оешманың күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсе шартларының үтәлмәве ачыкланса, җирле үзидарә органы, тиешле мөрәҗәгать итү көненнән унбиш көннән дә соңга калмыйча, мондый идарәче оешма белән шартнамәне өзү турындагы һәм яңа идарәче оешма сайлап алу турындагы яисә әлеге йорт белән идарә итү ысулын үзгәртү турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен шушы йорттагы урыннар милекчеләренең җыелышын җыя.

*(2015 елның 9 апрелендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Җирле үзидарә органнары гражданнарга аларның гарызнамәләре буенча күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне һәм алардагы торак урыннарны тоту һәм ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләргә һәм эшләргә билгеләнгән бәяләр (тарифлар) турындагы, билгеләнгән бәяләр (тарифлар) нигезендә түләү күләмнәре турындагы, күрсәтелә



г) эш бирүчеләр тарафыннан үзләренең хезмәткәрләренә, шул исәптән инвалидлык яисә яше буенча пенсиягә чыгу сәбәпле эштән киткән элекке хезмәткәрләренә күрсәтелә торган матди ярдәм;

д) авторлык хокукы һәм катнаш хокуклар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә, шул исәптән авторлыкны мирас итеп алу шартнамәләре буенча алына торган авторлык түләүләре;

е) крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат буларак төзелгән хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүдән алынган керемнәр;

ж) акцияләрдән алынган керемнәр һәм оешма милкенә идарә итүдә катнашудан алынган башка керемнәр;

з) алына торган алиментлар;

и) банк кертемнәре буенча процентлар;

к) мирас итеп алына торган яисә бүләк ителгән акчалар;

л) гражданнарга социаль ярдәм чаралары буларак бирелә торган һәм торак урыннар, коммуналь яисә транспорт хезмәте күрсәтүләр өчен түләүгә бәйле акчалата түләүләр;

м) торак урын, коммуналь һәм транспорт хезмәте күрсәтүләр өчен түләү буенча гражданнарга бирелә торган, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалары тарафыннан билгеләнгән, гражданнарга түләүне киметү рәвешендә бирелгән ташламаларның һәм социаль ярдәм чараларының акча эквивалентлары;

н) торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен аерым категорияләрдәге гражданнарга түләнә торган компенсацияләр;

о) опекага алынучыны карап тоткан өчен опекунга (попечительгә) бирелә торган акчалар;

п) гариза бирүченең яисә аның гаилә әгъзаларының мәгариф оешмаларында белем алуы өчен түләүгә тотылган теләсә нинди чыганаклардан алынган акчалар (гариза бирүченең яисә аның гаилә әгъзаларының үз акчаларыннан тыш);

р) түбәндәге законнар нигезендә билгеләнгән төрле категорияләрдәге гражданнарга айлык акчалата түләүләрнең һәм компенсацияләрнең суммалары:

«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы;

«Ветераннар турында» Федераль закон;

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон;

«Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль закон;

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми прин-

циплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль закон;

с) күрсәтелгән дәүләт социаль ярдәме суммалары.

### 7 статья. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган керем күләмен ачыклаганда исәпкә алынмый торган керем төрләре

1. Гражданнарның керемнәренә түбәндәгеләр керми:

1) кешенең гомеренә һәм сәламәтлегенә, аның шәхси мөлкәтенә һәм аның гаилә әгъзалары белән уртак милектәге мөлкәтенә китерелгән зыянны каплау өчен бер тапкыр түләнә торган иминият түләүләре, шулай ук дәүләт медик-социаль экспертиза хезмәте учреждениесе карары нигезендә медицина, социаль һәм һөнәри реабилитацияләүгә өстәмә чыгымнар белән бәйле айлык суммалар;

2) дәүләт социаль ярдәме турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әйберләтә ярдәм рәвешендә күрсәтелә торган дәүләт социаль ярдәме;

3) эшсез гражданнарга халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте тәкъдиме буенча башка җиргә эшкә (укуга) юллану сәбәпле түләнә торган матди чыгым компенсацияләре;

4) күмү өчен пособие;

5) төрле категорияләрдәге гражданнарга түбәндәге законнар нигезендә түләнә торган еллык компенсацияләр һәм берьюлы (бер тапкыр) бирелә торган пособиеләр:

а) «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы;

б) «Ветераннар турында» Федераль закон;

в) «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон;

г) «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль закон;

д) «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль закон.



6) федераль законнарда каралган башка хокукларга.

*(2015 елның 9 апрелендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4. *Үз көчен югалтты.*

*(2015 елның 9 апрелендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

*(статья 2012 елның 23 ноябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

### $6^2$ статья. Республика дәүләт торак күзәтчелеге органының муниципаль торак контроле органнары белән хезмәттәшлек итү тәртибе

1. Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы һәм муниципаль торак контроле органнары тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә түбәндәге мәсьәләләр буенча хезмәттәшлек итәләр:

1) республика дәүләт торак күзәтчелеген, муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар һәм методик документлар турында мәгълүмат бирү;

2) үткәрелә торган тикшерүләр нәтиҗәләре, тикшерелә торган торак фондының техник торышы, торак өлкәсендәге законнарның үтәлеше турында муниципаль торак контроле органнары тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелегенең вәкаләтле органына мәгълүмат бирү;

3) план буенча уртак тикшерүләр үткәрү максатларын, күләмен, срокларын билгеләү;

4) республика дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру өлешендә законнарны камилләштерү турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр әзерләү;

5) муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы белгечләрнең квалификациясен күтәрү;

6) республика дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органының муниципаль торак контроле органнары белән хезмәттәшлек итүе буенча административ регламентлар кабул итү.

2. Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органының һәм муниципаль торак контроле органнарының килештерелгән гамәлләрен тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрен, шул исәптән план буенча һәм планнан тыш уртак тикшерүләр үткәрү буенча да, җайга салуны гамәлгә ашыра.

*(статья 2012 елның 23 ноябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

Торак кодексының 20 статьясындагы $4^1$ һәм $4^2$ өлешләрендә каралган үзенчәлекләрен исәпкә алып, гамәлгә ашырыла.

3. Муниципаль торак инспекторлары федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан һәм гражданнардан дәлилләнгән язма гарызнамәләр нигезендә соратып алуга;

2) хезмәт таныклыгын һәм муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерү билгеләү турындагы боерыгының (күрсәтмәсенең) күчермәсен күрсәтеп, территориягә һәм анда урнашкан күпфатирлы йортларга, социаль файдаланудагы наем йортларына, күпфатирлы йортлардагы гомуми файдалану урыннарына тоткарлыксыз кереп йөрүгә; күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре ризалыгы белән торак урынларга кереп йөрүгә һәм аларны өйрәнүгә; тикшеренүләр, сынаулар, тикшерүләр, экспертиза уздыруга, социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннарны наемга бирүчеләрнең мондый йортларда торак урыннарны наемга бирүчеләргә һәм наемга алучыларга, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләрен һәм торак урыннарына наем шартнамәләрен төзүгә һәм үтәүгә карата мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен, Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{18}$ статьясындагы 2 өлешендә каралган затларның социаль файдаланудагы наем йортларын муниципаль реестрда исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрне раслый торган документларны тапшыру таләпләрен үтәвен тикшерүгә һәм контрольлек итү буенча башка чаралар үткәрүгә;

3) мәҗбүри таләпләрне бозуларны туктату турында, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең срокларын күрсәтеп, һәм (яисә) кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә зыян китерүне булдырмый калу чаралары, федераль законнарда каралган башка чаралар уздыру турында күрсәтмәләр бирүгә;

4) ачыкланган хокук бозуларны бетерүне контрольдә тоту, аларны кисәтү, гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү ихтималын булдырмый калу чараларын, шулай ук ачыкланган хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чараларын күрүгә, шул исәптән административ җаваплылык каралган мәҗбүри таләпләрне бозуларга бәйле материалларны административ хокук бозу турында эш кузгату мәсьәләсен хәл итү өчен компетенциясенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органына җибәрүгә; мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материалларны җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату мәсьәләләрен хәл итү өчен вәкаләтле органнарга җибәрүгә;

5) Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 6 өлешендә билгеләнгән очракларда судка мөрәҗәгать итүгә;



2. Гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның керемённән алар тарафыннан түләнгән алимент суммалары алына.

3. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган керемне исәпләгәндә, аларның булу урыннары буенча түбәндәгеләр тарафыннан алынган керемнәр исәпкә алынмый:

1) сержантлар, старшиналар, солдатлар яисә матрослар буларак чакырылу буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр, шулай ук хәрби профессиональ белем бирү оешмаларында һәм югары белемнең хәрби белем бирү оешмаларында белем алучы һәм хәрби хезмәтне узу турында контрактлар төземәгән хәрби хезмәткәрләр;

2) ирекtән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтәүче затлар, сак астына алу рәвешендә чикләү чарасы кулланылган, шулай ук суд карары буенча мәҗбүри дәваланудагы затлар;

3) интернат тибындагы учреждениеләрдә тулысынча дәүләт тәэминатында яшәүче затлар;

4) хәбәрсез югалган һәм эзләү гамәлләре башкарыла торган затлар.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән гражданнар өчен аларның кайда булуларына бәйсез рәвештә алына торган керемнәр (банклардагы, бүтән кредит учреждениеләрендәге кертемнәр буенча алынган керемнәр, күчмә һәм (яисә) күчемсез мөлкәтне наемга яисә өстәмә наемга бирүдән алынган керемнәр, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән башка керемнәр) исәпкә алына.

## 8 статья. Аерым категорияләрдәге гражданнарның керемнәрен билгеләү үзенчәлекләре

1. Хезмәткә яраклы балигъ булган гражданнарны хисап чоры дәвамында керемнәре булмаган дип тану, алар гаризада үз керемнәрен, шул исәптән хезмәт һәм (яисә) индивидуаль эшкуарлык эшчәнлегеннән кергән керемнәрен, хисап чорының бер ае буенча да раслый алмаган яки мөстәкыйль рәвештә декларация тутыра алмаган очракларда яисә үзләренең нульгә тигез керемнәрен раслый торган документларны тапшырганда, җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бу вакытта хисап чоры булып Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә наем шартнамәләрен төзүгә хокукы булган гражданнарны исәпкә кую (алга таба – наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗларны исәпкә кую) турында гариза бирелгән айдан алда килгән бер елга тигез чор санала.

2. Урта һөнәри яисә югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучылардан тыш, хисап чоры дәвамында керемнәре булмаган дип танылган хезмәткә яраклы балигъ булган гражданнар гаилә әгъзаларының гомуми составыннан чыгарыла. Бу очракта гаиләнең гомуми уртача айлык кереме гаилә әгъзаларының гомуми санына түгел, ә хисап чорында керемнәре булмаган, хезмәткә яраклы балигъ булган гаилә әгъзалары санына киметелгән санга бүленә.

3. Әгәр гражданнар, хезмәт һәм индивидуаль эшкуарлык эшчәнлегеннән алынган керемнәрдән тыш, үзләренең нинди дә булса керемнәрен документлар нигезендәраслый алмаса, аларга гаризада мондый керемнәренә мөстәкыйль декларация тутыру хокукы бирелә.

4. Салым салуның һәм гомуми, һәм гадиләштерелгән системасын, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен салым салу системасын (бердәм авыл хуҗалыгы салымы) кулланучы индивидуаль эшкуарларның керемнәрен индивидуаль эшкуарның керемнәрне һәм чыгымнарны, шулай ук хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсендәге белешмәләр белән расларга кирәк.

5. Әгәр салым салу объекты тиешле чыгымнар зурлыгына киметелмәгән керемнәрдән гыйбарәт булса, ул вакытта индивидуаль эшкуарлар хисап чорындагы чыгымнарны раслый торган беренчел исәпкә алу документларын күрсәтәләр.

6. Аерым төр эшчәнлек өчен булырга мөмкин керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын кулланучы индивидуаль эшкуарларның керемнәре үткән салым чоры өчен салым декларацияләренең декларацияләрне кабул итү турында салым органы тамгасы булган күчермәләре белән раслана.

7. Гражданның һәр гаилә әгъзасының керемен исәпләп чыгарганда, хезмәт хакын, хезмәт өчен түләү системасында каралган һәм ай буе эшләү нәтиҗәләре буенча түләнә торган компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне, айлык социаль түләүләрне һәм башкаларны да үз эченә алган барлык керемнәрнең суммасы хисап чорына керүче фактта алу аенда исәпкә алына.

8. Компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне үз эченә алган хезмәт хакын исәпләп чыгаруга һәм түләүгә башка сроклар билгеләнгәндә, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр белән бергә алынган хезмәт хакы суммасы әлеге хезмәт хакы исәпләнгән айлар санына бүленә һәм гражданның хисап чорына туры килә торган айлар керемнәрендә исәпкә алына.

9. Вакытлы хезмәт шартнамәләре буенча башкарыла торган сезонлы, вакытлыча һәм башка төрле эшләр өчен түләү, граждан-хокукый характердагы шартнамәләрне үтәүдән алынган керемнәр, шулай ук эшкуарлык һәм башка төр эшчәнлектән алынган керемнәр суммалары аларны алган айлар санына бүленә һәм гражданнарның хисап чорына туры килә торган айлар керемнәрендә исәпкә алына.

10. Гражданнар – крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзалары тарафыннан алынган керемнәр әлеге хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган уңышлардан, продукциядән һәм керемнәрдән файдалану турында крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзалары арасында законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелгән килешүдә (шартнамәдә) күрсәтелгән күләмнәреннән чыгып исәпкә алына.



ларын, гомумйорт ихтыяҗлары өчен коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын, җир кишәрлегеннән һәм ишегалды корылмаларыннан файдаланганда коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын билгелиләр;

5) коммуналь комплекс оешмалары тарифларын һәм өстәлмәләрен җайга салу өлкәсендә республика дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашыралар;

6) коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә билгеләнгән тарифларның муниципаль берәмлекләр буенча билгеләнгән иң чик үзгәрү индексларын куллануга республика дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашыралар;

7) торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарның түләү күләменең муниципаль берәмлекләр буенча билгеләнгән иң чик үзгәрү индексларын куллануга республика дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашыралар;

8) электр энергиясенең һәм куәтенең күпләп сату һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итү оешмалары, җылылык челтәрләре оешмалары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартлары үтәлүгә республика дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) гамәлгә ашыралар;

9) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

6[1] статья. **Татарстан Республикасында муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе**

1. Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру максатларында муниципаль берәмлек уставы һәм башка муниципаль хокукый актлар белән:

1) җирле үзидарәнең муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнары, аларның оештыру структурасы, вәкаләтләре, функцияләре һәм эшчәнлек тәртибе билгеләнә;

2) җирле үзидарәнең күрсәтелгән вәкаләтле органнары вазыйфаи затларының (алга таба – муниципаль торак инспекторлары) исемлеге һәм аларның вәкаләтләре раслана;

3) муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентлары кабул ителә.

2. Муниципаль торак контроле «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән рәвешләрдә, нигезләрдә, срокларда һәм даимилектә, план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр оештыруның һәм үткәрүнең Россия Федерациясе

ларының, технологик һәм техник стандартларда билгеләнгән таләпләргә туры килүенә һәм торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләренең һәм нормаларының үтәлүенә;

13) коммуналь хезмәтләр күрсәтү сыйфатының, күләменең һәм тәртибенең үтәлүенә, коммуналь хезмәтләр (җылылык, электр, су, газ белән тәэмин итү, су бирү) күрсәтүне тәэмин итүнең норматив дәрәҗәсен һәм режимын үтәү өлешендә гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең үтәлүенә һәм торак йортларда энергия һәм су ресурсларын җайга салу, тикшереп тору һәм исәпләү җайланмаларының булуына;

14) социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннар бирүгә торак законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәүгә;

*(14 пункт 2015 елның 9 апрелендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

15) коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүгә чикләүләрне үтәүгә.

*(15 пункт 2015 елның 9 апрелендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

2. Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлегенә лицензия бирә.

*(2 өлеш 2015 елның 9 апрелендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

### 6 статья. **Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары вәкаләтләре**

Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары үз компетенциясе чикләрендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар:

1) Татарстан Республикасы өчен тарифларны һәм өстәлмәләрне җайга салу өлкәсендә, алар билгеләнгән очракта, федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән иң чик индекслар нигезендә, аларга өстәлмәләрне исәпкә алып, коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә билгеләнгән тарифларның максималь мөмкин булган үзгәрү индексларын уртача муниципаль берәмлекләр буенча билгелиләр;

2) муниципаль берәмлекләр буенча гражданнарның торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләме үзгәрүнең иң чик индексларын законнар нигезендә билгелиләр;

3) коммуналь комплекс оешмалары товарларыннан һәм хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийлар системасын урнаштыралар;

4) торак урыннарда коммуналь хезмәтләрдән файдалану норматив-



11. Күчемсез һәм башка төр мөлкәтне арендага (наемга, субарендага, өстәмә наемга) бирүдән алынган керемнең суммасы керем алынган айлар санына бүленә һәм гражданнарның хисап чорына туры килә торган айлар керемнәрендә исәпкә алына.

12. Гражданнар тарафыннан белешмәләрдә күрсәтелгән керемнәр законнар нигезендә барлык салымнарны һәм җыемнарны түләгәннән соң кала торган күләмдә исәпкә алына.

### 9 статья. **Аерым категорияләрдәге гражданнар керемнәрен исәпкә алуның һәм мөлкәтләренең хакын билгеләүнең үзенчәлекләре**

1. Ялгыз яшәүче ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, бөтен хисап чорында яисә аның бер өлешендә мәгариф һәм башка оешмаларда, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, тәрбиягә алган гаиләләрдә, гаилә тибындагы балалар йортларында яшәгән балаларның керемнәре аларның күрсәтелгән оешмаларда яшәгән айлары өчен тиешле социаль-демографик төркемгә туры килә торган яшәү минимумына тигез дип санала.

2. Хисап чорында сержантлар, старшиналар, солдатлар яисә матрослар буларак чакырылыш буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр, шулай ук хәрби һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белемнең хәрби белем бирү оешмаларында белем алучы һәм хәрби хезмәт узу турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләр; ирегеннән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтәүче затлар; сак астына алу рәвешендә чикләү чарасы күрелгән затлар; суд карары буенча мәҗбүри дәваланудагы затлар; законлы көченә кергән суд карары нигезендә кайда булуы билгесез дип танылган затлар; интернат тибындагы учреждениеләрдә тулысынча дәүләт тәэминатында яшәүче затлар арасыннан булган ялгыз яшәүче гариза бирүчеләрнең булу урыннары буенча алынган керемнәре, әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, тиешле социаль-демографик төркем өчен яшәү минимумына тигез дип танылa.

3. Әлеге статьяның 1, 2 өлешләрендә күрсәтелгән затлар законлы нигезләрдә аларныкы булган күчемсез мөлкәтнең аларның файдалануына күчә алмавы турындагы белешмәләрне (суд бәхәсләре, билгеләнгән тәртиптә хокук теркәлгән торак урынга чынбарлыкта кереп урнашу мөмкин булмау, күрсәтелгән затка караган мөлкәт өлешен сату мөмкин булмау очракларында, бүтән төрле чикләүләр булганда) раслаган очракларда, аларныкы булган күчемсез мөлкәтнең хакы нульгә тигез дип танылa. Мөлкәттән файдалану мөмкин булмавы турында белешмәләрне раслау гражданның булу урыны буенча опека һәм попечительлек органнары тарафыннан яисә тиешле документлар нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10 статья. **Һәр гражданга туры килә торган керем күләмен билгеләү**

1. Һәр гражданга туры килә торган керем күләме әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә тапшырылган документлар һәм белешмәләр нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан исәпләп чыгарыла.

2. Һәр гаилә әгъзасының яисә гариза биргән ялгыз яшәүче гражданның уртача айлык кереме аның хисап чорында алынган керемнәре суммасын аның әлеге керемнәре булган айлар санына бүлү юлы белән исәпләп чыгарыла. Һәр гаилә әгъзасының уртача айлык керемнәре суммасы хисап чорында гаиләнең уртача айлык гомуми керемен тәшкил итә.

3. Хисап чорында һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык гомуми керем гаиләнең хисап чорындагы уртача айлык гомуми керемен гариза биргән гражданның гаилә әгъзалары санына бүлеп исәпләп чыгарыла.

4. Хисап чорында һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керем күләмен хисап чорындагы айларның санына һәм гаилә әгъзаларының санына тапкырлау хисап чорында гаиләнең гомуми керемен тәшкил итә.

11 статья. **Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында исәпкә алына торган мөлкәт**

1. Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану өчен гражданнарның милкендә булган, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакы исәпкә алына.

2. Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында исәпкә алына торган мөлкәткә түбәндәгеләр керә:

1) торак йортлар, фатирлар, дачалар, гаражлар һәм бүтән төзелмәләр, биналар һәм корылмалар;

2) законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән автомобильләр, мотоцикллар, мотороллерлар, автобуслар һәм башка үзйөрешле машиналар, шулай ук пневматик һәм чылбыр белән йөрешле механизмнар, самолетлар, вертолетлар, теплоходлар, яхталар, паруслы суднолар, катерлар, карда йөрү машиналары, моточаналар, моторлы көймәләр, гидроцикллар, үзе йөрми торган (буксирга алына торган суднолар) һәм башка су һәм һава транспорт чаралары;

3) торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативларындагы пай җаелмалары;

4) мөлкәт һәм җир өлешләренең (пайларының) хакы, бәяләрендә күрсәтелгән валютадагы кыйммәтләр һәм кыйммәтле кәгазьләр;



*(2015 елның 9 апрелендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

1) халыкка торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның хокуклары тәэмин ителүгә;

2) идарәче оешма эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чыгымнарны исәпләү тәртибенең үтәлүенә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буларак халыктан җыелган акчаларның максатчан тотылуына;

3) гамәлдәге норматив-техник һәм проект документлары нигезендә күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне тоту һәм ремонтлау эшләренең вакытында башкарылуына;

4) күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеге стандартларының һәм кагыйдәләренең үтәлүенә;

5) бюджет акчаларын һәм халыктан кергән акчаларны, шулай ук «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелә торган акчаларны кулланып, күпфатирлы йортларга хезмәт күрсәтү һәм капиталь ремонт ясау буенча эшләр башкару өчен идарәче оешма тарафыннан подрядчы оешмаларны сайлап алу (җәлеп итү) тәртибенең үтәлүенә;

6) күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары буенча торак урын өчен гражданнар түләвен формалаштыру (күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне тотуга, агымдагы эксплуатацияләүгә, капиталь ремонтлауга гражданнар түләвен формалаштыру) тәртибенең үтәлүенә;

7) коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар түләвен формалаштыру тәртибенең үтәлүенә;

8) күпфатирлы йорттагы биналар милекчеләре һәм идарәче оешмалар арасында шартнамәләр булуга һәм алардагы шартларның үтәлүенә;

9) идарәче оешманы энергия ресурслары белән тәэмин итүгә, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан гражданнарны энергия ресурслары белән тәэмин итүгә (йорт белән турыдан-туры идарә иткәндә) һәм идарәче оешмалар белән шартнамәләр нигезендә кулланучыларга һәм гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр булуга һәм ресурслар белән тәэмин итүче һәм коммуналь предприятиеләр тарафыннан шартнамәчел йөкләмәләрнең үтәлүенә (башкарылуына);

10) идарәче оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүенә;

11) милекчелек рәвешенә бәйсез рәвештә, торак фондыннан, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең уртак мөлкәтеннән файдалануга һәм аларның сакланышына һәм күпфатирлы йорттагы торак урыннардан файдалану кагыйдәләренең һәм уртак мөлкәтне тоту кагыйдәләренең үтәлүенә;

12) торак йортларның, торак урыннарның һәм күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең уртак мөлкәтенең техник торышының, шул исәптән инженерлык җайланмаларының, йорт эчендәге газ җайланма-

3 статья. **Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә хокукый җайга салу**

Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, әлеге Закон һәм шулар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары һәм муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

4 статья. **Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы торак фонды белән идарә итү;

*(2016 елның 9 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2) күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча адреслы региональ программаларны раслау һәм күпфатирлы йортларны шушы программаларга кертү шартларын билгеләү;

3) товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче идарәче оешмаларга субсидияләр бирүне (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шул исәптән мондый субсидияләрне бирү шартларын җайга сала торган, норматив хокукый актларны законнар нигезендә чыгару;

4) торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасында гражданнарга хокук белеме бирүне һәм юридик ярдәм күрсәтүне оештыру;

5) федераль законнарда, Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм Татарстан Республикасы законнарында, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары белән килешүләрдә билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы вәкаләтләре**

1. Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы түбәндәгеләргә республика дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыра:



5) территориясендә Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә җир салымы кертелгән муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре.

12 статья. **Гражданнарның гомуми өлеш милкендә яисә гражданнарның һәм юридик затларның гомуми өлеш милкендә йә гомуми уртак милектә булган мөлкәтне исәпкә алу үзенчәлекләре**

Салым салу объекты дип танылган мөлкәт берничә гражданның гомуми өлеш милкендә яисә гражданнарның һәм юридик затларның гомуми өлеш милкендә булган очракларда, шулай ук салым салу объекты дип танылган мөлкәт берничә физик затның гомуми өлеш милкендә булса, гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда, салымны түләүчесе мондый граждан һәм (яисә) аның гаилә әгъзалары булган мөлкәт салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә исәпкә алынырга тиеш.

13 статья. **Хисап чорында сатылган мөлкәтне исәпкә алу үзенчәлекләре**

Әгәр салым салынырга тиешле һәм гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану өчен исәпкә алына торган мөлкәт исемлегенә керүче мөлкәт гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гариза биргән граждан тарафыннан хисап чорында сатылган булса, сатылган мөлкәтнең хакы хисап чоры дәвамында булган мөлкәт хакы буларак исәпкә алына, моңа гариза биргән гражданнар тарафыннан тапшырыла торган тиешле документлар белән расланган мәҗбүри сату (ашыгыч медицина дәвалануы, кыйммәтле дарулар һ.б. өчен түләү) очраклары керми.

14 статья. **Гражданнар милкендәге күчемсез мөлкәтнең хакын билгеләү**

1. Гражданнар милкегендәге күчемсез мөлкәтнең хакы күчемсез мөлкәтне кадастр исәбенә куюны һәм дәүләт кадастрын алып баруны башкара торган органнан тиешле салым органнары алган мәгълүматлар нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә. Граждан яисә җирле үзидарә органы күчемсез мөлкәтнең кадастр хакы белән килешмәгән очракта, мөлкәтнең базар хакы кулланыла, шул ук вакытта күчемсез мөлкәтне бәяләү буенча тиешле чыгымнарны кадастр бәясе белән килешмәгән зат каплый.

2. Җир кишәрлекләренең хакы җирле үзидарә органы тарафыннан җирнең кадастр бәясе турындагы мәгълүматлар нигезендә билгеләнә.

15 статья. **Гражданнарның башка төр мөлкәтләре хакын билгеләү**

1. Гражданнар милкендәге һәм исәпкә алынырга тиешле транспорт чараларының хакы гражданнарның үз хисабына үткәрелә торган транспорт чараларын бәяләү турындагы бәяләү эшчәнлеге субъектының хисабы нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

2. Торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативларындагы пай җыелмаларының хакын билгеләү гариза биргән граждан тарафыннан тапшырылган һәм торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативлары таныклаган белешмәләргә таянып башкарыла.

16 статья. **Наем шартнамәләре буенча торак урыннар алуга хокукны кабат раслау максатларында гражданнарның керемнәре һәм мөлкәтләренең хаклары күләмен яңадан бәяләү**

1. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар исәбенә алынган гражданнарның керемнәрен һәм мөлкәтләренең хакын яңадан бәяләү, наем шартнамәләре буенча торак урыннар алуга аларның хокукын раслау максатларында, җирле үзидарә органы тарафыннан ел саен 1 гыйнвардан алып 1 майга кадәр әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

2. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар исәбенә куелган гражданнарның керемнәрен һәм мөлкәтләренең хакларын яңадан бәяләүне уздыру өчен, әгәр гражданнар үз теләкләре белән тиешле документларны тапшырмаган булсалар, җирле үзидарә органы 1 апрельгә кадәр түбәндәге документларны соратып алырга тиеш:

1) мөлкәткә хокукларны дәүләт исәбенә алу һәм теркәү органнарыннан һәм тиешле органнардан гражданнарның милек хокукындагы салым салынырга тиешле күчемсез һәм күчемле мөлкәтләренә ия булуларының хокукый нигезләрен раслый торган документларның күчермәләрен;

2) узган салым чорындагы керемнәре турында салым декларацияләренең салым органы тамгасы куелган күчермәләрен яисә гражданнарны аз керемле дип тану турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган гражданнар керемнәрен раслый торган башка документларны;

3) әлеге Законның 17 статьясындагы 1 өлешендә каралган документларны (граждан тарафыннан тапшырыла торган гаризадан тыш).

3. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар исәбенә алынган гражданнарның керем күләмен һәм мөлкәт хакын яңадан бәяләү түбәндәге рәвештә башкарыла:

1) гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

*(2012 елның 23 ноябрендәге 77-ТРЗ номерлы,
2015 елның 9 апрелендәге 19-ТРЗ номерлы,
2016 елның 9 июлендәге 62-ТРЗ номерлы
Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы һәм максатлары**

1. Әлеге Закон күпфатирлы йортлар белән идарә итү, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең уртак мөлкәтен тоту, коммуналь хезмәтләр күрсәтү, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертү өлкәсендә гражданнарның торак хокукларын яклауны, шул исәптән республика дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру юлы белән, тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

2. Әлеге Закон Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибен һәм муниципаль торак контролен оештырганда һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органының муниципаль торак контроле органнары белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгели.

*(2012 елның 23 ноябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатлары өчен идарәче оешмалар дигәндә күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затлар яисә барлык оештыру-хокукый рәвешләрдәге индивидуаль эшкуарлар дип аңларга кирәк.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр Россия Федерациясе Торак кодексындагы мәгънәсендә кулланыла.

юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм гражданнар тарафыннан торак фондыннан милек рәвешләренә бәйсез рәвештә файдалануга һәм аны саклауга федераль законнар нигезендә билгеләнгән таләпләрне, шул исәптән капиталь ремонт фондларын булдыруга, региональ оператор булдыруга һәм аның эшчәнлегенә таләпләрне бозуларны кисәтүгә, ачыклауга һәм булдырмауга юнәлдерелгән эшчәнлеген федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

13 статья. **Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәмен бирү тәртибе һәм шартлары**

1. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме (алга таба – дәүләт ярдәме) чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга каралган ассигнованиеләр чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт ярдәме Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә төзелгән торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш кооперативларына, идарә итүче оешмаларга, региональ операторга Россия Федерациясе Торак кодексы, башка федераль законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бирелә.

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Капиталь ремонт буенча региональ программаларны гамәлгә ашыру кысаларында дәүләт ярдәме урыннар милекчеләре тарафыннан кулланыла торган капиталь ремонт фонды булдыру алымына бәйсез рәвештә бирелә.

14 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай дәвамында шушы Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 25 июне
№ 52-ТРЗ



хакының максималь күләме кимегәндә, гражданнарны исәпкә алу вакытына гамәлдә булган күрсәткечләр кулланыла;

2) гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының кереме һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләме артканда керемнең һәм мөлкәт хакының яңа билгеләнгән максималь күләме кулланыла.

4. Керемнәр һәм мөлкәт хакы күләме керемнең һәм мөлкәт хакының максималь күләменә тигез яисә аннан арткан очракта, гражданнар наем шартнамәләре буенча торак урыннар алу хокукын югалта.

17 статья. **Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлеге, шулай ук аларны тапшыру тәртибе**

1. Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен түбәндәге документлар кирәк:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән форма буенча гариза, ул граждан белән бергә даими яшәүче хокукка сәләтле барлык гаилә әгъзалары тарафыннан имзалана;

2) гражданның һәм аның белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының паспортлары яисә шәхесне таныклаучы башка документларның күчермәләре;

3) гражданның гаилә составы турындагы документларның (туу турында таныклык, язылышу турында таныклык, уллыкка алу (кызлыкка алу) турында карар, гаилә әгъзасы итеп тану турында суд карары һ.б.) күчермәләре;

4) йорт кенәгәсеннән өземтә;

5) граждан һәм аның гаилә әгъзалары яши торган торак урыннан файдалану хокукын раслаучы документларның (шартнамә, ордер, торак бинаны бирү турында карар һәм башка төрле документлар) күчермәләре;

6) гаилә әгъзаларының даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннар булу яисә булмау турында дәүләт теркәве органнарыннан белешмә, ул гаризаны бирү вакытына кадәрге биш ел өчен гариза бирүченең хокукка сәләтле һәр гаилә әгъзасы тарафыннан тапшырыла.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1, 2 һәм 3 пунктларында, әлеге Законның 8 (5 өлешеннән тыш), 13 һәм 15 статьяларында күрсәтелгән документлар гражданнар тарафыннан тапшырыла.

3. Әлеге Законның 1 өлешендәге 4 – 6 пунктларында һәм 15 статьясында күрсәтелгән документлар гражданнар тарафыннан үз теләге белән тапшырылырга мөмкин, ә тапшырылмаган очракта күрсәтелгән документлар җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт органнарын-

да, җирле үзидарәнең башка органнарында йә аларның буйсынуындагы оешмаларда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып алына.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документлар төп нөсхәләрендә дә, гаризаны бирү урыны буенча җирле үзидарә органы яисә тиешле документны биргән оешмалар тарафыннан таныкланган йә нотариаль таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла.

5. Җирле үзидарә органнары сорату нигезендә тапшырылган һәм алынган документларны һәм белешмәләрне дәүләт хакимияте органнарына, салым һәм таможня органнарына, башка оешмаларга рәсми соратулар җибәрү юлы белән тикшерергә хокуклы.

6. Гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар тапшырылган документларның һәм белешмәләрнең дөреслеге өчен законнар нигезендә җаваплы була. Гаризада керемнәр һәм мөлкәтләр турында тапшырылган белешмәләрне җирле үзидарә органы тарафыннан салым, таможня һәм башка органнарда тикшерүгә карата гражданның һәм аның балигъ булган гаилә әгъзаларының ризалыгы белдерелгән булырга тиеш.

18 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән башлап өч ай эчендә әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 16 марты
№ 13-ТРЗ

2. Региональ оператор Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органына урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортлар турында, шулай ук мондый күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләреннән капиталь ремонт өчен кертемнәрнең керүе турында түбәндәге белешмәләрне тапшырырга тиеш:

1) күпфатирлы йортка идарә итү алымын сайлап алу турында урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәләренең күчермәләре;

2) күпфатирлы йорт турында мәгълүмат (күпфатирлы йортның ничә катлы булуы, гомуми мәйданы, күпфатирлы йорттагы торак урыннарның мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлгән гражданнар саны, файдалануга тапшыру елы, соңгы капиталь ремонт елы);

3) урыннар милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фонды булдыруның сайлап алынган алымы турында хәбәрнамә;

4) капиталь ремонт фонды булдыру алымын сайлап алу турында урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәләренең күчермәләре;

5) *үз көчен югалтты;*

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6) реквизитларны күрсәтеп, региональ оператор счетын, счетларын ачу турында белешмә;

7) урыннар милекчеләреннән капиталь ремонт өчен кертемнәрнең региональ оператор счетына, счетларына керүен раслый торган документлар;

8) региональ оператор счетында, счетларында калган акчаларның күләме турында мәгълүмат.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында каралган белешмәләр махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органына махсус счет ачылган вакыттан биш эш көне дәвамында, шул исәптән электрон рәвештә дә, Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы билгеләгән тәртиптә тапшырыла. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 һәм 3 пунктларында һәм 2 өлешендә каралган белешмәләр региональ оператор, махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органына ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның беренче числосына кадәр, шул исәптән электрон рәвештә дә, Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы билгеләгән тәртиптә тапшырыла.

4. Дәүләт торак күзәтчелеге органы әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләр реестрын, махсус счетлар реестрын алып бара, җирле үзидарә органына һәм региональ операторга урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын булдыру алымын сайлап алмаган һәм (яисә) аны гамәлгә ашырмаган күпфатирлы йортлар турында хәбәр итә.

5. Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук

1) техник критерийлар:

а) күпфатирлы йортта капиталь ремонт планлаштырыла торган гомуми мөлкәт объектларының техник торышы;

б) файдалануга тапшырылганнан соң яисә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә соңгы комплекслы капиталь ремонттан соң күпфатирлы йортны эксплуатацияләү дәвамлылыгы;

в) проект документациясен әзерләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә кирәк булган очракта, мондый документациянең булуы;

г) күпфатирлы йортта энергетика тикшерүе нәтиҗәләре буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелгән энергетика паспортының булуы;

2) оештыру критерийлары:

а) урыннар милекчеләренең капиталь ремонт ясау турындагы карарны хуплау дәрәҗәсе;

б) җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр исәбен булдыру һәм үткәрү эшләрен башкаруны раслый торган документларның булуы;

3) капиталь ремонтны финанслауда урыннар милекчеләренең өлешен билгели торган финанс критерие.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән чиратлылык билгеләү критерийларын куллану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

12 статья. **Капиталь ремонт фонды булдыруны тикшереп тору**

1. Махсус счет хуҗасы Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органына түбәндәге белешмәләрне тапшырырга тиеш:

1) тиешле күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фонды булдыруның сайлап алынган алымы турында хәбәрнамә, аңа түбәндәгеләр кушып бирелә:

а) Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләрендә каралган карарларны кабул итү турында урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсенең күчермәсе;

б) махсус счет ачу турында банк белешмәсе;

в) күпфатирлы йортка идарә итү алымын сайлап алу турында урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәләренең күчермәләре;

г) күпфатирлы йорт турында мәгълүмат (күпфатирлы йортның ничә катлы булуы, гомуми мәйданы, күпфатирлы йорттагы торак урыннарның мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлгән гражданнар саны, файдалануга тапшыру елы, соңгы капиталь ремонт ясау елы);

2) капиталь ремонт фондларын махсус счетта булдыручы урыннар милекчеләреннән капиталь ремонт өчен кертемнәрнең керүен раслый торган документлар;

3) махсус счетта калган акчаларның күләме турында мәгълүмат.



«Социаль файдаланудагы торак фондының
торак урыннарына наем шартнамәләре
буенча гражданнарның торак урыннары алу
хокукларын гамәлгә ашыру турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы**

1. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар алуның базар хакын исәпләү күрсәткече (алга таба – исәп күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ,

монда:

СЖ – исәп күрсәткече;

НП – муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзаларының саны;

РЦ – торак урындагы бер квадрат метрның муниципаль берәмлектәге уртача шартларга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урыннарны алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар хакыннан артып китми торган уртача исәпләнгән базар бәясе.

2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖ исәпләү күрсәткеченә тигез итеп кабул ителә.

Гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма кеременең максималь күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1) торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган, СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, ул түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 – (1 + ПС) $^{–КП}$) / (0,25 х РС),

монда:

ПД – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ – исәп күрсәткече;

ПС – кредит буенча бер айга процент ставкасы (унарлы вакланма);

КП – кредитның барлык срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС – гаилә әгъзаларының саны;

0,7 – кредит суммасының фатир хакына карата нисбәте;

0,25 – кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма керемевә карата нисбәте;

2) торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булмаган муниципаль берәмлекләрдә – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм, социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урын алу чиратында уртача көтү вакытына тигез итеп карала торган муниципаль берәмлектә билгеләнгән уртача туплау чорын исәпкә алып, СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алу өчен акча туплауга кирәкле булган уртача айлык җыелма керем күләменнән чыгып. Бу вакытта тупланмаларның Татарстан Республикасында минималь куллану бюджетының уртача зурлыгына тигез яисә аннан кимрәк керем алганда җыела алмавы исәпкә алына.

Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләмен билгеләү өчен түбәндәге формула кулланыла:

а) социаль файдаланудагы торак фонды милекчесе үзенә караган урыннарны наемга бирүдән керем алуны планлаштырса:

ПД = (СЖ / ПН) / РС + ПБ x 1,02,

монда:

ПД – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ – исәп күрсәткече;

ПН – тупланмаларның билгеләнгән чоры (айлар саны);

РС – гаилә әгъзаларының саны;

ПБ – бер кешегә уртача айлык керемнең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән минималь күләме (бер типтагы гаилә әгъзасына минималь куллану бюджеты);

б) социаль файдаланудагы торак фонды милекчесе үзенә караган урыннарны наемга бирүдән керем алырга ниятләмәсә (әгәр торак дәүләт һәм муниципаль торак фондларыннан бирелсә):

ПД = (СЖ / ПН) / РС + ПБ,

монда:



срокларын конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төрләрен төгәлләштерү, капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзе билгеләгән тәртиптә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы (еллык) планнарын расларга тиеш. Җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актында капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслау каралган булса, шушы норматив хокукый актта билгеләнгән тәртиптә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын расларга тиеш.

*(2016 елның 3 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

$11^1$. Региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнары түбәндәге принциплардан чыгып төзелә:

1) Россия Федерациясе Торак кодексының 185 статьясында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, региональ оператор счетындагы, счетларындагы алдагы елда файдаланылмый калган акчаларны һәм агымдагы елда капиталь ремонт өчен кертемнәр керүнең фаразланган күләмен капиталь ремонт максатларына тоту;

2) региональ оператор счетында, счетларында капиталь ремонт өчен акча җыелуның факттагы дәрәҗәсеннән чыгып, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча эшләр күләмен төзәтү кирәклеге.

*($11^1$ өлеш 2016 елның 3 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

11 статья. **Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү критерийлары**

1. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгы капиталь ремонт буенча региональ программада әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән критерийлар нигезендә билгеләнә.

2. Капиталь ремонт буенча региональ программада беренче чиратта капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау яисә актуальләштерү датасына мондый капиталь ремонт ясалмаган булса, беренче торак урынны хосусыйлаштыру датасына капиталь ремонт ясау таләп ителгән күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау күздә тотылырга тиеш.

*(2014 елның 14 маендагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү критерийлары түбәндәгеләр:

кон үз көченә кергән көннән ике айдан да соңга калмыйча җирле үзидарә органы тарафыннан вәкаләтле органга тапшырыла.

8. Муниципаль адреслы программалар һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган белешмәләр нигезендә вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә капиталь ремонт буенча региональ программа проектын төзи һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслау өчен җибәрә.

9. Капиталь ремонт буенча региональ программа кимендә елга бер тапкыр актуальләштерелергә тиеш.

10. Капиталь ремонт буенча региональ программаны актуальләштергәндә аңа күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның билгеләнгән срогын соңрак чорга күчерүне, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төре исемлеген кыскартуны күздә тота торган үзгәрешләр кертү урыннар милекчеләре гомуми җыелышының тиешле карары булганда гамәлгә ашырыла, аңа түбәндәге очраклар керми:

1) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча планлаштырылган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төренең исемлеген кыскарту капиталь ремонт үткәрелергә тиешле конструктив элементларның булмавына бәйле булса;

2) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яки) эшләрнең планлаштырылган төрләре алданрак үткәрелгән булса һәм шул ук вакытта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә яңадан мондый хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән срокта таләп ителми дип табылса;

3) капиталь ремонт фонды булдыру ысулын үзгәртү Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясының 7 өлешендә каралган нигезләрдә башкарылса. Бу очракта капиталь ремонт ясау вакыты күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә ачыклана.

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы, 2016 елның 3 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

$10^{1}$. Капиталь ремонт буенча региональ программага үзгәрешләр кертү турындагы карарлар торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы раслаган методик тәкъдимнәр нигезендә кабул ителә.

*($10^{1}$ өлеш 2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

11. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау



ПД – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керемнең максималь күләме;

СЖ – наем шартнамәсе нигезендә торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакын исәпләү күрсәткече;

ПН – тупланмаларның билгеләнгән чоры (айлар саны);

РС – гаилә әгъзаларының саны;

ПБ – бер кешегә җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән уртача айлык минималь дәрәҗә (бер типтагы гаилә әгъзасына минималь куллану бюджеты).

3. Гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче гражданның торак урын сатып алу өчен наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасыннан түбән булмаган күләмдәге җитми торган акчалары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПЖ = СЖ – И,

монда:

ПЖ – торак урын өчен акчаларга ихтыяҗ;

СЖ – исәп күрсәткече;

И – гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле, гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүдә мохтаҗлар категориясенә кертү кертүкәндә исәпкә алына торган мөлкәт хакының күләме.

4. Ипотека кредиты алу мөмкинлеген бәяләү түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПЛТ = ПЖ х ПС / (1 – (1 + ПС) $^{–КП}$),

монда:

ПЛТ – ипотека кредиты буенча ай саен түләнә торган сумма;

ПЖ – торак урын өчен акчаларга ихтыяҗ;

ПС – кредит буенча айлык процент ставкасы (унарлы вакланма);

КП – кредитның барлык срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны).

5. Гаиләнең ай саен, П/ДС, О/ДС, ПЖ/СЖ коэффициентларын кулланып, ПЛТ күләмендә кредит каплау мөмкинлеге:

1) П/ДС <= 30%,

монда:

П – заемга алучының торак өчен айлык чыгымнары, моңа төп бурыч буенча айлык түләү һәм ипотека кредиты буенча процентлар (ПЛТ) түләү, мөлкәткә салым буенча айлык түләүләр, күчемсез мөлкәтне иминләштерү, шулай ук заем алучының гомерен иминләштерү буенча айлык түләүләр дә керә;

ДС – гаиләнең уртача айлык җыелма кереме (керем салымын тотып калып);

2) О/ДС <= 40%,
монда:

О – турыдан-туры кредитлар (П) түләүгә, шулай ук заем алучының озак сроклы (кагыйдә буларак, бер елдан артык) башка йөкләмәләренә бәйле (куллану кредитларына, башка бурыч йөкләмәләренә, шулай ук алиментларга, тәрбиясендә булганнарны карап тотуга, сәламәтлекне медицина иминләштерүенә яисә пенсия тупланмаларына (контрактлар һәм шартнамәләр нигезендә өстәмә рәвештә), күчемле һәм күчемсез мөлкәтне иминләштерүгә һәм башка төрле мәҗбүри даими түләүләргә бәйле) чыгымнарны исәпкә алган айлык мәҗбүри түләүләрнең гомуми суммасы;

ДС – гаиләнең уртача айлык җыелма кереме (керемгә салымны исәпкә алып).

6. Гаиләнең торак урын сатып алу өчен җитми торган акчаны туплый алу мөмкинлеге түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Н = (ДС – СПБ) х ПН,
монда:

Н – билгеләнгән чорда гаиләнең мөмкин булган тупланмалары күләме;

ДС – гаиләнең уртача айлык җыелма кереме;

СПБ – гаиләгә исәпләгәндә уртача айлык минималь керем дәрәҗәсе (бер типтагы гаилә әгъзасына минималь куллану бюджеты күләмен гаилә әгъзалары санына тапкырлап исәпләнә);

ПН – тупланмаларның билгеләнгән чоры (айларда).

7. Гражданны наем шартнамәләре буенча торак урын алуга мохтаҗ дип тану турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) җитми торган акча күләме гаиләнең аны туплау мөмкинлегеннән артыграк булса (ПЖ > Н), ә гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме торак бина сатып алу яисә төзү өчен кредит алуны дәгъва кылырга мөмкинлек бирмәсә (П/ДС > 30% яисә О/ДС > 40%) – гражданны наем шартнамәсе буенча торак урын алуга мохтаҗ дип тану турында карар кабул ителә;

2) гаиләнең акча туплау мөмкинлекләре җитми торган акча күләменә тигез яисә аннан артыграк булса (Н >= ПЖ) – гражданны наем шартнамәсе буенча торак урын алуга мохтаҗ дип танымау турында карар кабул ителә;

3) җитми торган акча күләме гаиләнең аны туплау мөмкинлегеннән артыграк булса (ПЖ > Н), ләкин гаилә торак бина сатып алуга яисә төзүгә кредит алуны дәгъва кыла алса (П/ДС <= 30%, О/ДС <= 40%),



1) капиталь ремонт буенча региональ программаның төп максатлары һәм бурычлары;

2) капиталь ремонт буенча региональ программаны үтәүнең планлаштырыла торган күрсәткечләре;

3) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан (шул исәптән барлык биналары бер милекчегә караган күпфатирлы йортлар) һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган муниципаль адреслы программаларга кертелгән барлык күпфатирлы йортлар исемлеге, моңа Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортлар керми;

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге;

5) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның план чоры, шул исәптән хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең һәр төре буенча башкару сроклары, шул ук вакытта күрсәтелгән срок календарь елны яисә мондый ремонт ясалырга тиешле өч календарь елдан артып китмәгән чорны күрсәтеп билгеләнергә мөмкин;

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6) капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән региональ оператор тарафыннан түләнергә мөмкин булган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясе күләме;

7) Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә капиталь ремонт буенча региональ программага кертелергә тиешле башка белешмәләр.

5. Күпфатирлы йортларга идарә итүче затлар әлеге Закон үз көченә кергән көннән бер ай дәвамында капиталь ремонт буенча региональ программаны төзү өчен җирле үзидарә органнарына үзләре идарә итә торган күпфатирлы йортлар турында вәкаләтле орган тарафыннан расланган рәвештә мәгълүмат тапшыралар.

6. Җирле үзидарә органы әлеге статьяның 5 өлешендә билгеләнгән срок тәмамланганнан соң бер ай дәвамында кергән мәгълүматны гомумиләштерә, шулай ук күпфатирлы йортларга идарә итүче затлар тарафыннан әлеге йортлар буенча тапшырылмаган мәгълүматны җыя. Гомумиләштерелгән мәгълүмат нигезендә җирле үзидарә органнары капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программа раслый.

7. Расланган капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программа һәм муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан барлык күпфатирлы йортлар турында гомумиләштерелгән мәгълүмат әлеге За-

рында карар яисә исәпкә кертүдән баш тарту хакында дәлилле карар кабул итә, шул хакта тиешле карар кабул итү датасыннан 10 көн дәвамында урыннар милекчеләренә хәбәр итә.

9 статья. **Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү тәртибе**

1. Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы раслаган методик рекомендацияләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

2. Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме, күпфатирлы йорттагы урын милекчесенә карый торган урынның гомуми мәйданыннан чыгып, күпфатирлы йортның төрен һәм ничә катлы булуын, күпфатирлы йорттагы төзелеш конструкцияләренең аерым элементларына һәм инженерлык системаларына капиталь ремонт ясау хакын, чираттагы капиталь ремонт ясаганчы алардан нәтиҗәле файдалануның норматив срокларын (ремонтара норматив сроклар), шулай ук күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Россия Федерациясе Торак кодексында, әлеге Законда билгеләнгән эшләр исемлеген исәпкә алып билгеләнә.

3. Вәкаләтле орган капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләүне һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслау өчен җибәрүне тәэмин итә.

10 статья. **Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа әзерләү һәм раслау тәртибе, мондый программаларга таләпләр, аларны әзерләү өчен кирәкле белешмәләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан бирү тәртибе**
*(исеме 2014 елның 14 маендагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

1. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны (алга таба – капиталь ремонт буенча региональ программа) әзерләү һәм раслау Россия Федерациясе Торак кодексы һәм әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Капиталь ремонт буенча региональ программа Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан барлык күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау өчен кирәкле срокка төзелә һәм даими нигездә гамәлдә була.

3. Капиталь ремонт буенча региональ программа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Капиталь ремонт буенча региональ программага түбәндәгеләр керә:



гражданны наем шартнамәсе буенча торак урын алуга мохтаҗ дип тану турында карар тиешле муниципаль берәмлектә торак урын сатып алуга яисә төзүгә торак кредитлары бирү базарының үсеш дәрәҗәсенә бәйле булырга мөмкин, ул:

а) торак сатып алуга кредит бирүне тәэмин итүче кредит оешмалары (ипотека, өлешләп төзү, торак-туплау кооперативлары һәм башкалар) булу-булмауга бәйле рәвештә;

б) торак кредитларын субсидияләү буенча региональ яисә муниципаль программалар булу-булмауга бәйле рәвештә;

в) банкның гариза биргән гражданга торак сатып алуга яисә төзүгә кредит бирү турында яисә кредит бирүдән баш тарту хакында конкрет карары белән билгеләнә.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2007 елның 14 июнендә
кабул ителде

*(2008 елның 5 августындагы 67-ТРЗ номерлы,
2008 елның 30 декабрендәге 150-ТРЗ номерлы,
2010 елның 24 июлендәге 56-ТРЗ номерлы,
2011 елның 13 декабрендәге 101-ТРЗ номерлы,
2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы,
2012 елның 29 сентябрендәге 68-ТРЗ номерлы,
2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы,
2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы,
2015 елның 16 мартындагы 15-ТРЗ номерлы
Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә түбәндәгеләрне билгели:

гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакын билгеләү тәртибен;

гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керемне һәм гаилә әгъзалары милкендәге салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакын исәпкә алып, муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарга торак урыннары бирү максатларында аларны аз керемле дип тану тәртибен;

Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен;

гражданнар торак урыннарына бәйле гамәлләр һәм граждан-хокукый алыш-бирешләр башкарган очракта, әгәр мондый гамәлләр башкару биләнә торган торак урыннарының күләмен киметүгә яисә аларны читләштерүгә китерсә, бирелә торган торак урынының гомуми мәйданын билгеләү тәртибен.



түләүне кертү өчен билгеләнгән срокларда түлиләр. Капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү документларында күрсәтелгән региональ операторның счетына күчерелә.

3. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү актлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итүдә урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар, шулай ук җирле үзидарә органнары катнаша.

4. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән срогы җиткәнче шушы күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада каралган аерым хезмәтләр күрсәтелгән һәм (яисә) аерым эшләр башкарылган булса, бу хезмәт күрсәтүләргә һәм (яисә) эшләргә түләү бюджет акчаларыннан һәм региональ оператор акчаларыннан файдаланмыйча гына гамәлгә ашырылган булса һәм шул ук вакытта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә әлеге хезмәтләрне яңадан күрсәтү һәм (яисә) эшләрне яңадан эшләү күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән срокта таләп ителмәсә, шушы хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең хакына тигез булган, әмма әлеге хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр хакының Россия Федерациясе Торак кодексының 190 статьясындагы 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменнән артык булмаган күләмдәге акчалар капиталь ремонт фондларын булдыручы урыннар милекчеләренең региональ оператор счетына, счетларына капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәләрен киләчәк чорга үтәү исәбенә кертеләләр.

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

5. Әлеге статьяның 4 өлешендә каралган очракта акчаларны исәпкә кертү капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыручы урыннар милекчеләренең йә урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларның үзләренең капиталь ремонт өчен кертемнәрне түләү буенча йөкләмәләрен киләчәк чорда үтәү исәбенә кертеп гамәлгә ашыру турында гариза белән региональ операторга мөрәҗәгать иткәндә башкарыла. Гаризага күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яисә) башкарылган эшләр өчен подряд оешмасына түләүне раслый торган документлар һәм әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә рәсмиләштерелгән, Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы һәм вәкаләтле орган белән килештерелгән күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү актлары кушып бирелә.

6. Региональ оператор тапшырылган документларның керү датасыннан 30 көн дәвамында аларны тикшереп чыга һәм исәпкә кертү ту-

1) йорт эчендәге электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су җибәрү инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру;

2) файдалану өчен яраксыз дип танылган лифт җиһазын ремонтлау яисә алмаштыру, лифт шахталарын ремонтлау, лифтларны диспетчерлаштыру системасы белән җиһазлау;

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3) түбә ремонтлау, шул исәптән җилләнми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп үзгәртеп кору, түбәгә чыгу җайланмалары ясау;

4) күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә карый торган идән асты бүлмәләрен ремонтлау;

5) фасадны җылыту һәм ремонтлау, халыкның азмобильле төркемнәре өчен күпфатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында подъездларга керү урыннарын пандуслар белән һәм баскычларны ике яктан култыксалар белән җиһазлау;

*(2016 елның 22 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6) коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслар куллануны исәпләүнең коллектив (гомумйорт) приборларын һәм әлеге ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) куллануга идарә итү һәм аны җайга салу узелларын урнаштыру яисә алмаштыру;

7) күпфатирлы йорт нигезен ремонтлау;

8) күпфатирлы йорттагы подъездларны ремонтлау;

9) күпфатирлы йортка энергетика тикшерүе үткәрү;

10) проект документациясенә дәүләт экспертизасы эшләү һәм үткәрү (проект документациясен әзерләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар нигезендә кирәк булган очракта);

11) төзелеш контролен башкару;

12) күпфатирлы йортның янгынга каршы саклану системасын ремонтлау;

13) күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү.

*(13 пункт 2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

2. Капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында булдырган очракта урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәрне күпфатирлы йортта торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне исәпләүче оешма тарафыннан бирелгән түләү документлары нигезендә, әгәр күпфатирлы йортка идарә итү шартнамәсе йә торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән бүтән срок билгеләнмәгән булса, узган айдан соң килүче айның беренче числосыннан да соңга калмыйча түлиләр. Урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәрне торак урынга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләргә



2 статья. **Төп төшенчәләр**

Вәкаләтле орган – муниципаль берәмлекнең гражданнарны аз керемле дип тану өчен яшәү урыны буенча әлеге Законда каралган гамәлләрне, шулай ук гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алуны гамәлгә ашыручы башкарма-боеру органы.

Исәп-хисап чоры – Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннары бирү өчен исәпкә кую турында гариза биргән айга кадәр булган бер елга тиң чор.

Керемнең иң чик күләме – гаиләнең һәр әгъзасының уртача айлык керемнәренең яисә мөрәҗәгать итүче ялгыз граждан кеременең вәкаләтле орган билгеләгән дәрәҗәсе.

Мөлкәт хакының иң чик күләме – гаилә әгъзалары милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең гомуми хакында һәр гаилә әгъзасына туры килә торган өлешнең яисә мөрәҗәгать итүче ялгыз яшәүче граждан мөлкәте хакының вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән күләме.

Гражданның гаилә әгъзалары – аның белән бергә яшәүче ире йә хатыны, шулай ук балалары һәм әлеге гражданның ата-анасы. Гражданның башка туганнары, аның каравындагы хезмәткә сәләтсез затлар аның гаилә әгъзалары буларак яшәгәндә һәм аның белән бергә гомуми хуҗалык алып барганда гаилә әгъзалары булып саналалар. Аерым очракларда башка затлар суд тәртибендә гаилә әгъзалары булып танылырга мөмкин.

3 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча торак урыннарына мохтаҗлар дип тану өчен нигезләре булган һәм әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары тарафыннан аз керемлеләр дип танылган яисә федераль закон, Россия Федерациясе Президенты указы яки Татарстан Республикасы законы белән аерым категориягә кертелгән затлар торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куела.

2. Гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алуны вәкаләтле орган шушы гражданнарның күрсәтелгән органга алар тарафыннан яшәү урыны буенча бирелгән яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге аша юлланган гаризалары нигезендә гамәлгә ашыра. Законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә гражданнар яшәү урыннарыннан читтә дә исәпкә кую турында гариза бирә алалар.

*(2015 елның 16 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Вәкаләтле органның социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу һәм исәптән төшерү тәртибен бозуда гаепле вазыйфаи затлары гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы булалар.

4 статья. **Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү**

Гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында граждан гаиләсенең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга (алга таба – гражданнар) туры килә торган керемнең һәм мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү әлеге Законга кушымта итеп бирелә торган Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Керемнең һәм мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен яңадан карау елга бер мәртәбә башкарыла.

5 статья. **Гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар дип тану өчен нигезләр**

Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә түбәндәге гражданнар танылa:

социаль наем шартнамәләре, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар булмаган яки социаль наем шартнамәсе, социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе буенча торак урынын яллаучының гаилә әгъзалары йә торак урыннарының милекчеләре яки торак урыны милекчесенең гаилә әгъзалары булмаган;

*(2015 елның 16 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

социаль наем шартнамәләре, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар булган яки социаль наем шартнамәсе, социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе буенча торак урынын яллаучының гаилә әгъзалары йә торак урыннарының милекчеләре яки торак урыны милекчесенең гаилә әгъзалары булган һәм



рергә тиешле акчаларның гомуми күләменнән 30 проценттан артыкны тәшкил итмәскә тиеш;

5) региональ операторның дебитор бурычы проценты региональ операторның агымдагы эшчәнлеген финанслауга каралган сметадагы гомуми күләмнең 30 процентыннан артмаска тиеш. Монда региональ оператор счетындагы, счетларындагы капиталь ремонт фонды акчалары исәпкә алынмый. Күрсәтелгән өлешне арттыру региональ операторның эшчәнлегенә тикшерү үткәрү һәм дебитор бурычны юк итүгә юнәлдерелгән өстәмә чаралар күрү өчен нигез булып тора.

7 статья. **Региональ оператор эшчәнлеген тикшереп тору**

1. Региональ оператор эшчәнлегенең законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшереп тору Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1[1]. Федераль башкарма хакимиятнең финанс-бюджет өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек вазыйфаларын башкаручы органы региональ операторның капиталь ремонтка дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм буларак бирелгән акчалардан, шулай ук региональ оператор счетында, счетларында капиталь ремонт фонды барлыкка китерә торган күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләреннән алынган акчалардан файдалануын Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тикшереп тора.

*(1[1] өлеш 2014 елның 14 маендагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

2. Татарстан Республикасының дәүләт финанс контроле органнары һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль финанс контроле органнары, Россия Федерациясе Хисап палатасы, Татарстан Республикасының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап һәм финанс органнары региональ операторның тиешле бюджетлар акчаларыннан файдалануга финанс контролен Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыралар.

3. Хокук бозулар ачыкланган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары ачыкланган закон таләпләрен бозуларны бетерү турында региональ операторга тәкъдимнәр һәм (яисә) күрсәтмәләр җибәрә.

8 статья. **Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру тәртибе**

1. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча капиталь ремонтка кертемнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында билгеләнгән минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финанслана торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлегенә түбәндәгеләр керә:

өчен җаваплы затка (торак милекчеләре ширкәтенә, торак кооперативына яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативына, идарә итүче оешмага) һәм, әлеге күпфатирлы йортта урыннар милекчеләре аңа турыдан-туры идарә иткәндә, Россия Федерациясе Торак кодексының 164 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затка тапшыра.

6 статья. **Региональ оператор эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгына таләпләр**

1. Региональ операторның күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны финанслауга ел саен тоту хокукы булган акчалар күләме (гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт киләсе чорда ясалырга тиешле күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре тарафыннан булдырылган капиталь ремонт фондлары акчалары исәбеннән бирелә торган акчалар күләме) региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменә һәм (яисә) агымдагы елда капиталь ремонт өчен кертемнәр керүнең фаразлана торган күләменә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән өлешнең күләме, региональ оператор тарафыннан алдагы чорда тотылмаган калган акчаларны исәпкә алып, региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменнән 92 процентны тәшкил итә.

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән керемнәр күләмен исәпләгәндә Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджетлардан һәм башка чыганаклардан алынган акчалар исәпкә алынмый.

3. Региональ оператор эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын тәэмин итүгә өстәмә таләпләр түбәндәгеләр:

1) региональ оператор тарафыннан вакытлыча ирекле акчаларны урнаштыру шартлары капиталь ремонт ясау буенча күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яисә) башкарылган эшләр өчен исәп-хисап ясаганда акчалар кытлыгы барлыкка килүгә, шул исәптән региональ оператор һәм капиталь ремонт ясау буенча хезмәтләр күрсәтүче һәм (яисә) эшләр башкаручы оешма арасында төзелгән шартнамәдә каралган җаваплылыкка региональ операторны тарту очрагына китермәскә тиеш;

2) региональ оператор тарафыннан вакытлыча ирекле акчаларны урнаштыру шартлары региональ операторның күрсәтелгән эшчәнлегеннән керемнәрнең даими артуын күздә тотарга тиеш;

3) кредитлар һәм (яисә) заемнар региональ оператор тарафыннан Региональ операторның попечительлек советы ризалыгы белән генә җәлеп ителергә мөмкин;

4) капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча региональ операторга бурыч проценты региональ операторга урыннар милекчеләреннән ке-



гомуми мәйданы гаиләнең бер әгъзасына исәпләнгән нормадан кимрәк булган торак урыны белән тәэмин ителгән;

*(2015 елның 16 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

торак урыннары өчен билгеләнгән таләпләргә җавап бирми торган урыннарда яшәүчеләр;

берничә гаилә яши торган фатирдагы гаилә составында бергә яшәргә ярамый торган хроник авыруның каты рәвешеннән интегүче авыру булган һәм социаль наем шартнамәсе, социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе буенча яки милек хокукында бүтән торак урыны булмаган һәм социаль наем шартнамәләре, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар, социаль наем шартнамәсе, социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе буенча торак урыны яллаучының гаилә әгъзалары яисә торак урынының милекчеләре, торак урыны милекчесенең гаилә әгъзалары булып торучы гражданнар. Мондый авырулар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

*(2008 елның 30 декабрендәге 150-ТРЗ номерлы, 2015 елның 16 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

6 статья. **Гражданнарны торак урынына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен, шулай ук керем күләмен һәм мөлкәт хакын билгеләү өчен кирәкле документлар исемлеге, аларны карау һәм теркәү тәртибе**

1. Гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен түбәндәге документлар кирәк:

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

а) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән рәвештәге, мөрәҗәгать итүче белән бергә яшәүче хокуктан файдалануга сәләтле барлык гаилә әгъзалары тарафыннан имзаланган гариза (алга таба – гариза);

*(«а» пунктчасы 2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

б) мөрәҗәгать итүче гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының паспортының яки шәхесен таныклаучы бүтән документларының күчермәләре;

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

в) мөрәҗәгать итүче гражданның гаилә составы турындагы документларының (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык,

уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы итеп тану турында суд карары һ.б.) күчермәләре;

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

г) мөрәҗәгать итүче гражданны йә аның гаилә әгъзасын торак законнары нигезендә чиратсыз торак алу хокукына ия граждannар категориясенә кертергә нигез бирә торган документлар:

торак йортны (торак урынын) яшәү өчен яраксыз дип тану турында федераль башкарма хакимият органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органы карары – граждан яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урынында яшәгән очракта;

медицина оешмасыннан медицина белешмәсе – гражданның гаилә составында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы расланган исемлек буенча бер фатирда бергә яшәргә ярамый торган хроник авыруның каты рәвешеннән интегүче авыру булганда;

*(2008 елның 5 августындагы 67-ТРЗ номерлы, 2008 елның 30 декабрендәге 150-ТРЗ номерлы, 2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

опекун билгеләү турында опека һәм попечительлек органнарыннан белешмә – исәпкә кую турындагы гариза хокуктан файдаланугa сәләтсез граждан исеменнән эш итүче опекун тарафыннан имзаланган очракта;

*(2008 елның 5 августындагы 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар статусын, мәгариф һәм башка оешмаларда, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә, гаилә тибындагы балалар йортларында булу вакыты тәмамлангач, опека (попечительлек) туктатылгач, шулай ук Россия Федерациясе Хәрби көчләрендә хезмәт үтү тәмамлангач яисә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән кайткач, аларның ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан чыккан затлар статусын раслый торган документлар;

*(2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

*(«г» пунктчасы 2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

д) йорт кенәгәсеннән өземтә;

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

е) мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыныннан файдалану хокукын раслый торган документларның



ук региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган башка күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны финанслау өчен файдаланылырга мөмкин. Акчалардан болай файдалану күрсәтелгән күпфатирлы йортлар бер муниципаль берәмлек территориясендә урнашканда гына рөхсәт ителә.

6. Татарстан Республикасы территориясендә бер региональ оператор төзелгән һәм эш иткән очракта, урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) капиталь ремонт эшләренең техник заказчысы функцияләре региональ оператор белән төзелгән тиешле шартнамә нигезендә җирле үзидарә органнары һәм (яисә) муниципаль бюджет һәм казна учреждениеләре тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6$^{1}$. Капиталь ремонт фондларын исәпкә алу системасын алып бару буенча региональ оператор функцияләре региональ оператор белән төзелгән шартнамә нигезендә дәүләт бюджет яисә казна учреждениесе рәвешендә төзелгән бүтән юридик зат тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу чакта региональ оператор мондый юридик зат гамәлләре өчен үз гамәлләре өчен җаваплы булган кебек үк җаваплы була.

*(6$^{1}$ өлеш 2014 елның 14 маендагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

6$^{2}$. Региональ оператор Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге вәкаләтле органында счетлар, махсус счетлардан тыш, ачарга хокуклы. Россия Федерациясе Торак кодексында каралган башка очракларда региональ оператор тарафыннан счетлар, махсус счетлар ачу Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән таләпләргә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурс нәтиҗәләре буенча региональ оператор тарафыннан сайлап алынган Россия кредит оешмаларында гамәлгә ашырыла. Мондый конкурс уздыру тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

*(6$^{2}$ өлеш 2014 елның 14 маендагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде, 2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы, 2016 елның 3 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

7. Региональ оператор эшчәнлеге турындагы мәгълүмат региональ операторның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

8. Региональ оператор Россия Федерациясе Торак кодексының 183 статьясындагы 2 өлешендә каралган белешмәләрне сорату буенча урыннар милекчеләренә, шулай ук бу күпфатирлы йортка идарә итү

1) капиталь ремонт фондлары региональ оператор счетында, счетларында булдырыла торган күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре тарафыннан түләнә торган капиталь ремонт өчен кертемнәрне туплау;

2) урыннар милекчеләренең гомуми җыелышында урыннар милекчеләре махсус счет хуҗасы буларак региональ операторны сайлаган очракта үз исеменә махсус счетлар ачу һәм әлеге счетлар буенча операцияләр башкару. Региональ оператор күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тарафыннан үз исеменә мондый счет ачудан баш тартырга хокуксыз;

3) урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча эшләрнең техник заказ бирүчесе функцияләрен гамәлгә ашыру;

4) урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт чыгымнарын әлеге капиталь ремонт фондлары акчалары чикләрендә, кирәк булганда, башка чыганаклардан, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яисә) җирле бюджеттан алынган акчаларны җәлеп итеп финанслау;

5) урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны үз вакытында ясауны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эш итү;

6) Россия Федерациясе Торак кодексында, әлеге Законда һәм региональ операторның гамәлгә кую документларында каралган башка функцияләр.

4. Региональ оператор күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада каралган күләмдә һәм срокларда урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында булдыра торган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны һәм аны финанслауны, шул исәптән капиталь ремонт фонды акчалары җитмәгән очракта, капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган башка күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең түләүләре исәбеннән алынган акчалар исәбеннән, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яисә) җирле бюджеттан алынган субсидияләр исәбеннән, закон белән тыелмаган башка акчалар исәбеннән тәэмин итә.

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

5. Региональ оператор тарафыннан капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган бер күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләреннән алынган акчалар кире кайтару нигезендә урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын шушы



(шартнамә, ордер, торак урыны бирү турында карар һәм бүтән документлар) күчермәләре;

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

ж) гаилә әгъзаларының даими яшәү урыны буенча милек хокукындагы торак урыннарының булуы яки булмавы турында дәүләт теркәве органнары белешмәсе, ул мөрәҗәгать итүче гаиләсенең хокуктан файдалануга сәләтле һәр әгъзасыннан гариза бирелгән елга кадәрге биш ел өчен тапшырыла.

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Гражданнарны аз керемлеләр дип тану өчен, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган документлардан тыш, өстәмә рәвештә түбәндәге документлар кирәк:

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

а) мөлкәти хокукларны дәүләт исәбенә алу һәм теркәү органнарыннан һәм башка органнардан гражданнарның салым салынырга тиешле күчемсез һәм күчемле мөлкәткә милек хокукында ия булуларының хокукый нигезләрен раслый торган документлар күчермәләрен;

б) узган салым чорына керемнәр турында салым декларацияләренең аларны кабул итү турында салым органы тамгасы белән күчермәләре, яисә гражданнарның аларны аз керемле дип тану турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган керемнәрен раслый торган башка документларны;

в) әлеге Законның 12, 18, 19 статьяларында күрсәтелгән башка документларны.

3. Гражданнарны федераль закон, Россия Федерациясе Президенты указы яисә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән категориягә кертүне раслау максатларында, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган документлар белән бергә, гражданнарны федераль закон, Россия Федерациясе Президенты указы яисә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән, торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алынырга хокукы булган башка категориягә кертүне раслый торган документлар кирәк.

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4. Гражданнарның гаризалары Торак урынына мохтаҗлар буларак исәпкә алу турында һәм аз керемлеләр дип тану турында гражданнар гаризаларын теркәү кенәгәсендә яисә Торак урынына мохтаҗлар буларак исәпкә алу турында гражданнар гаризаларын теркәү кенәгәсендә (алга таба – гаризалар теркәү кенәгәләре) теркәлә. Гаризалар теркәү кенәгәләренең рәвеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4[1]. Әлеге статьяның 1 өлешендәге «а», «б», «в» һәм «г» (икенче абзацтан тыш) пунктчаларында, әлеге Законның 12 (4 өлешеннән тыш), 17, 19 һәм 20 статьяларында күрсәтелгән документлар гражданнар тарафыннан тапшырыла.

Әлеге статьяның 1 өлешендәге «д» – «ж» пунктчаларында, 2 өлешендәге «а» һәм «б» пунктчаларында, 3 өлешендә, әлеге Законның 18 статьясында күрсәтелгән документларны гражданнар үз инициативалары белән тапшырырга мөмкин, ә тапшырылмаган очракта бу документлар законнар нигезендә алар белән эш итүче дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалардан (алга таба – оешмалар) вәкаләтле орган тарафыннан соратып алына.

*(4[1] өлеш 2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

5. Вәкаләтле орган гариза биргән гражданнарга, тапшырылган документларның кабул ителүе турында аларның исемлеген һәм алыну датасын күрсәтеп, шулай ук ведомствоара гарызнамәләр буенча алыначак документлар исемлеген күрсәтеп Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән рәвештә расписка бирә.

*(2012 елның 29 сентябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6. Гражданны социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ буларак тану нигезләре булганда, гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында вәкаләтле орган гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керемнең исәп-хисабын башкара һәм гражданның, аның гаилә әгъзаларының милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакын билгели.

### 7 статья. Документлар тапшыру

1. Әлеге Законның 6 статьясындагы 1 – 3 өлешләрендә күрсәтелгән документлар беренче нөсхәләрендә, шулай ук исәпкә алу турында гариза бирелгән урындагы вәкаләтле орган йә тиешле документны биргән оешмалар тарафыннан танылланган, йә нотариаль расланган күчермәләрендә тапшырыла.

*(2008 елның 5 августындагы 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Вәкаләтле органнар тапшырылган һәм соратып алынган документларны һәм белешмәләрне дәүләт хакимияте органнарына, салым һәм таможня органнарына, бүтән оешмаларга рәсми үтенечнамәләр җибәрү юлы белән тикшерергә хокуклы.

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар тапшырылган документларның һәм белешмәләрнең дөреслеге



3) үз исеменә махсус счет ачылган зат һәм региональ оператор тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 177 статьясындагы 7 өлеше һәм 183 статьясы нигезендә тапшырылырга тиешле белешмәләрне тапшыру тәртибен билгеләү;

4) *үз көчен югалтты;*

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

5) Россия Федерациясе Торак кодексында, әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

### 4 статья. Җирле үзидарә органнарының күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча вәкаләтләре

Җирле үзидарә органнарының күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслау;

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2) Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда региональ оператор счетында капиталь ремонт фонды булдыру турында карарлар кабул итү;

3) Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа һәм региональ оператор тәкъдимнәре нигезендә капиталь ремонт ясау турында карарлар кабул итү;

4) федераль законнарда һәм әлеге Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

### 5 статья. Региональ оператор эшчәнлеге мәсьәләләре

1. Региональ оператор фонд оештыру-хокукый рәвешендәге төзелгән юридик зат булып тора. Региональ оператор Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә төзелә.

2. Региональ оператор эшчәнлеге, Россия Федерациясе Торак кодексы, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Региональ операторның функцияләре түбәндәгеләр:

рында урыннар милекчеләре тарафыннан карар кабул итүнең һәм аны гамәлгә ашыруның срогын билгеләү;

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

12) региональ операторның еллык бухгалтерлык (финанс) хисабына аудит үткәрү турында карар кабул итүнең, аудитор оешмасы (аудитор) белән шартнамәне раслау тәртибен билгеләү, конкурс нигезендә аудитор оешмасын (аудиторны) сайлап алуны башкару;

13) региональ операторның еллык хисабын һәм аудитор бәяләмәсен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта урнаштыру тәртибен һәм срокларын билгеләү;

$13^{1}$) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген ачыклау тәртибен билгеләү;

*($13^{1}$ пункт 2014 елның 14 маендагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

$13^{2}$) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр өчен «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм фонды турында» Федераль законның $20^{1}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә ачылган махсус счетларга салынган акчалар исәбеннән түләү тәртибен билгеләү;

*($13^{2}$ пункт 2014 елның 14 маендагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

$13^{3}$) капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында, счетларында булдырган очракта региональ оператор тарафыннан яисә капиталь ремонт фондын махсус счетта булдырган очракта махсус счет хуҗасы тарафыннан, капиталь ремонт фонды булдыру алымы үзгәргәндә, тиешенчә махсус счет хуҗасына һәм (яисә) региональ операторга капиталь ремонт фонды булдыруга бәйле булган барлык документларны һәм мәгълүматны тапшыру тәртибен билгеләү;

*($13^{3}$ пункт 2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

14) Россия Федерациясе Торак кодексында һәм әлеге Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Архитектура, шәһәр корылышы, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендәге, торак һәм коммуналь хуҗалык өлкәсендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының (алга таба – вәкаләтле орган) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) күпфатирлы йортларның техник торышына мониторинг үткәрү тәртибен билгеләү;

2) урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны үз вакытында ясауны тәэмин итү максатларында региональ оператор белән үзара эш итү;



өчен законнар нигезендә җаваплы була. Гаризада керемнәр һәм мөлкәт турында тапшырылган белешмәләрне салым, таможня һәм бүтән органнарда вәкаләтле орган тарафыннан тикшерүгә гражданның һәм аның балигъ булган гаилә әгъзаларының ризалыгы бәян ителергә тиеш.

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4. *Үз көчен югалтты.*

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

8 статья. **Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу һәм исәпне алып бару**

1. Гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу (исәпкә алудан баш тарту) турындагы карар әлеге Законның 6 статьясында күрсәтелгән документларның тулы комплекты тапшырылган һәм (яисә) соратып алынган көннән башлап утыз эш көненнән дә соңга калмыйча вәкаләтле орган тарафыннан мөстәкыйль рәвештә кабул ителә. Исәпкә алудан баш тарту турындагы карар гражданның үзе катнашында вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә, бу хакта документларны карау урыны һәм вакыты күрсәтелгән хәбәрнамә җибәрелә.

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы, 2012 елның 29 сентябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

2. Вәкаләтле орган, шул исәптән күпфункцияле үзәк аша да, исәпкә алу турында карар кабул ителгән көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле гариза биргән гражданга аны исәпкә алу турындагы карарны бирә яисә җибәрә. Граждан күпфункцияле үзәк аша исәпкә алынуы турында гариза тапшырган очракта, гариза бирүче карарны алуның бүтән рәвешен күрсәтмәсә, гражданны исәпкә алу турындагы карар күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

*(2012 елның 29 сентябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Гражданнар вәкаләтле орган тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән исәпкә алынган дип санала.

Берьюлы берничә гражданның гаризасы каралганда, аларның чираты гаризаны һәм әлеге Законның 6 статьясы нигезендә күрсәтелгән документларны тапшыру вакытыннан чыгып билгеләнә.

*(2012 елның 29 сентябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4. Исәпкә алынган гражданнар Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу кенәгәсенә (алга таба – Гражданнарны исәпкә алу кенәгәсе) кертелә, ул вәкаләтле орган тарафыннан алып барыла. Гражданнарны исәпкә алу

кенәгәсенең рәвеше һәм аны алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5. Гражданнарны исәпкә алу кенәгәсендә төзәтмәләр кертү рөхсәт ителми. Документлар нигезендә кертелә торган төзәтмәләр һәм үзгәрешләр социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның исәбен алып бару өчен җаваплылык йөкләнгән вазыйфаи зат тарафыннан раслана.

6. Торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алынган һәр гражданга кирәкле документлар кертелгән исәп эшнамәсе ачыла. Исәп эшнамәсенә Гражданнарны исәпкә алу кенәгәсендәге номерга туры килә торган номер бирелә. Исәп эшнамәсенең рәвеше һәм аны алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

7. Вәкаләтле орган гаризаларны теркәү кенәгәләрен, Гражданнарны исәпкә алу кенәгәсен һәм исәп эшнамәләрен тиешенчә саклауны тәэмин итә.

8. Граждан үтенечнамәсе буенча вәкаләтле орган билгеләнгән тәртиптә бирелгән номер, чиратлылык турында белешмә бирергә тиеш.

9 статья. **Гражданнарны аз керемлеләр дип тану нигезләре**

Һәр гражданга туры килә торган керем күләме һәм гражданнар милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы керемнең иң чик күләменнән һәм мөлкәт хакыннан артып китмәгән очракта, вәкаләтле орган карары нигезендә гражданнар социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан аларга торак урыннары бирү максатларында аз керемлеләр дип танылa.

10 статья. **Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган керемнәрнең төрләре**

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләмен аларны аз керемлеләр дип тану өчен исәпләгәндә гражданның һәм аның гаиләсенең һәр әгъзасының яисә ялгыз яшәүче гражданның акчалата һәм натуралата алган керемнәренең барлык төрләре исәпкә алына, шул исәптән:

а) законнар нигезендә уртача хезмәт хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган хезмәт өчен түләү системасында каралган барлык түләүләр;

б) хезмәт законнарында каралган очракларда сакланып кала торган уртача хезмәт хакы;

в) дәүләти яки иҗтимагый бурычларны башкарган вакытта дәүләт органы яки иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсация;

г) эштән азат ителгәндә түләнә торган пособие, отставкага чыкканда бирелә торган компенсация, оешма ябылуга, эшчеләрнең саны яки



1) капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү;

2) Татарстан Республикасы тарафыннан бирелә торган дәүләт ярдәме акчалары исәбеннән финансланырга мөмкин күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеген билгеләү;

3) региональ оператор төзү, региональ операторның мөлкәтен формалаштыру һәм эшчәнлеге тәртибен билгеләү, конкурс нигезендә региональ оператор җитәкчесен билгеләп кую тәртибен, региональ операторның гамәлгә кую документларын раслау;

*(2014 елның 20 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программага кертелергә тиешле өстәмә белешмәләрне билгеләү;

5) өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслау тәртибен билгеләү;

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6) өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслау;

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

7) капиталь ремонт өчен кертемнәр исәбеннән формалаштырылган акчаларның саклануын тәэмин итүне һәм шушы акчаларның максатчыл тотылуын тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

8) региональ оператор эшчәнлегенең законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

9) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яисә) күрсәтелгән хезмәтләрне урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында кабул итү тәртибен билгеләү;

10) урыннар милекчеләренә махсус счет хуҗасы һәм (яисә) региональ оператор тарафыннан капиталь ремонт фонды акчаларын түләү һәм җибәрү тәртибен, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда капиталь ремонт фонды акчаларыннан күпфатирлы йортны сүтү яисә реконструкцияләү максатларында файдалану тәртибен билгеләү;

11) әлеге Законның 2 статьясындагы $4^1$ өлешендә билгеләнгән очрактан тыш, капиталь ремонт фонды булдыру алымын билгеләү ту-

2) капиталь ремонт өчен кертемнәрне урыннар милекчеләренең региональ операторга карата йөкләмә хокуклары рәвешендә капиталь ремонт фонды булдыру максатларында региональ оператор счетына күчерү.

7. Капиталь ремонт фонды булдыру алымы Россия Федерациясе Торак кодексы белән билгеләнгән тәртиптә урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары нигезендә теләсә кайсы вакытта үзгәртелергә мөмкин.

8. Махсус счет банкта Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә һәм Россия Федерациясе Торак кодексы белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып ачыла.

9. Үз исеменә махсус счет ачыла торган зат (алга таба – махсус счет хуҗасы) түбәндәгеләр булырга мөмкин:

1) күпфатирлы йортка идарә итүне гамәлгә ашыручы һәм бер күпфатирлы йортта яисә берничә күпфатирлы йортта урыннар милекчеләре тарафыннан оештырылган торак милекчеләре ширкәте Россия Федерациясе Торак кодексының 136 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә;

*(2014 елның 20 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы, 2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

2) күпфатирлы йортка идарә итүне гамәлгә ашыручы торак кооперативы;

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

$2^1$) күпфатирлы йортка идарә итүне идарә итү шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашыручы идарә итүче оешма;

*($2^1$ пункт 2014 елның 20 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде, 2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3) урыннар милекчеләре гомуми җыелышта региональ операторны махсус счет хуҗасы буларак сайлау турында карар кабул иткән очракта күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган махсуслаштырылган оешма (алга таба – региональ оператор).

10. Региональ оператор Россия Федерациясе Торак кодексы, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы тарафыннан төзелә.

3 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:



штаты кыскартылуга бәйле эштән азат ителгәндә эшкә урнашу чорына саклана торган хезмәт хакы;

д) барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлардан, бюджеттан тыш дәүләт фондларыннан һәм башка чыганаклардан социаль түләүләр, аларга түбәндәгеләр керә:

пенсияләр, компенсация түләүләре (эшкә сәләтсез гражданнарны карый торган эшләмәүче эшкә яраклы затларга компенсация түләүләреннән тыш) һәм пенсионерларны ай саен өстәмә матди тәэмин итү;

отставкага чыккан судьяларга гомер буе ай саен акчалата түләү;

стипендияләр, шул исәптән студентларга дәүләт академик стипендиясе, студентларга дәүләт социаль стипендиясе, бюджет ассигнованиеләре хисабына көндезге уку бүлегендә белем алучы аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясе, мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән стипендияләр һәм акчалата түләүләр;

*(2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

эшсезлек буенча пособие, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм бүтән түләүләр, шулай ук эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри әзерләнү, яңа һөнәргә өйрәнү һәм квалификация күтәрү чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм, иҗтимагый эшләрдә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга вакытлыча эшләрдә катнашкан чордагы түләүләр, шулай ук 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга вакытлыча эшләрдә катнашкан чордагы түләүләр;

вакытлыча эшкә сәләтсез булу буенча пособие, йөклелек һәм бала табу буенча пособие, шулай ук йөклелекнең башлангыч срокларында медицина оешмаларында исәпкә куелган хатын-кызларга бер тапкыр түләнә торган пособие;

*(2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

балага айлык пособие;

балага яшь ярым тулганчы аны карау буенча отпуск чорына айлык пособие һәм хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы һәм балага өч яшь тулганчы аны карау буенча отпусктагы гражданнарга компенсация түләүләре;

контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең хатыннарына айлык пособие – алар белгечлек буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмауга бәйле рәвештә эшләмәскә мәҗбүр булган яки эшкә урнаша алмаган җирлекләрдә ирләре белән яшәгән һәм билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган чорда, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары ирләренең хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартларына бәйле балаларының сәламәтлеге торышы буенча, әгәр аларның балалары 18 яше

тулганчы медицина оешмасы бәяләмәсе буенча кеше тәрбиясенә мохтаҗ булса, эшләмәскә мәҗбүр булган чорда;

*(2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының җинаять-башкарма системасы учреждениеләренең эшкә урнаштыру мөмкинлекләре булмаган ерак урнашкан гарнизоннарындагы һәм җирлекләрдәге гади һәм җитәкче составындагы затларның эшләмәүче хатыннарына айлык компенсация түләүләре;

производстводагы бәхетсезлек очракларыннан һәм профессиональ авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү буенча айлык иминият түләүләре;

әлеге пунктчада күрсәтелгән түләүләрнең барлык төрләренә өстәмәләр һәм өстәлмәләр һәм Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан билгеләнгән бүтән социаль түләүләр;

е) гаиләнең (аның аерым әгъзаларының) яки ялгыз яшәүче гражданның милек хокукындагы мөлкәтеннән керемнәр, аларга түбәндәгеләр керә:

күчемсез мөлкәтне (җир кишәрлекләрен, йортларны, фатирларны, дачаларны, гаражларны), транспорт һәм бүтән механик чараларны, продуктларны эшкәртү һәм саклау чараларын реализацияләүдән һәм арендага (субарендага, наемга, поднаемга) бирүдән керемнәр;

хосусый ярдәмче хуҗалык уңышларын һәм продукциясен (күпьеллык үсентеләрне, бакча продукциясен, продукция һәм күргәзмә хайваннарын, кош-кортларны, кыйммәтле мехлы хайваннарны, бал кортларын, балыкларны) реализацияләүдән керемнәр.

Күрсәтелгән керемнәргә җир кишәрлегендә алынган һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан шәхси куллану өчен файдаланылган уңышлар һәм продукция керми;

ж) гаиләнең һәм ялгыз яшәүче гражданның башка керемнәре, аларга түбәндәгеләр керә:

хәрби хезмәткәрләрнең һәм Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының җинаять-башкарма системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм хокук саклау хезмәтенең башка органнары хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән даими характердагы өстәмә түләүләр һәм азык-төлек белән тәэмин итү (азык-төлек паегы урынына акчалата компенсация);

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының җинаять-башкарма системасы учреждениеләреннән һәм органнарыннан, Россия Федерациясе таможня органнарыннан, хокук саклау хезмәтенең башка органнарыннан эштән азат ителгәндә бер мәртәбә түләнә торган пособие;



геләнгән күләмдә яисә, урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән булса, зуррак күләмдә капиталь ремонт өчен айлык кертемнәр түләргә тиеш.

4. Әлеге статьяның 4[1] өлешендә билгеләнгән очрактан тыш, урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы әлеге күпфатирлы йорт кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча расланган региональ программа рәсми басылып чыккан айдан соң килә торган айдан башлап ике календарь ай үткәннән соң барлыкка килә.

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4[1]. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа расланганнан соң эксплуатациягә кертелгән һәм аны актуальләштергәндә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программага кертелгән күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы шушы күпфатирлы йорт кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа рәсми басылып чыккан айдан соң килә торган айдан башлап биш календарь ай үткәннән соң барлыкка килә. Капиталь ремонт фонды булдыру алымын билгеләү турында карар урыннар милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы барлыкка килгәнче өч айдан да соңга калмыйча кабул ителергә һәм гамәлгә ашырылырга тиеш.

*(4[1] өлеш 2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

5. Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәт объектларын файдалануга бирүдән керемнәр, торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы акчалары, шул исәптән торак милекчеләре ширкәтенең, торак кооперативының хуҗалык эшчәнлегеннән алынган керемнәр, Россия Федерациясе Торак кодексы, торак милекчеләре ширкәте уставы, торак кооперативы уставы нигезендә кабул ителгән урыннар милекчеләре карары, торак милекчеләре ширкәте әгъзалары карары, торак кооперативы әгъзалары карары буенча урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычын үтәү исәбенә капиталь ремонт фонды булдыруга һәм (яисә), капиталь ремонт өчен кертемнең билгеләнгән минималь күләменнән чыгып, булдырыла торган капиталь ремонт фонды өлешенә өстәп капиталь ремонт фонды өлешен булдыруга юнәлдерелергә мөмкин, ул күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча теләсә кайсы хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләрне финанслау өчен тотылырга мөмкин.

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6. Урыннар милекчеләре капиталь ремонт фонды булдыруның түбәндәге алымнарыннан берсен сайлап алырга хокуклы:

1) капиталь ремонт өчен кертемнәрне махсус счеттагы акчалата капиталь ремонт фонды булдыру максатларында махсус счетка күчерү;

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 30 маенда
кабул ителде

*(2014 елның 14 маендагы 37-ТРЗ номерлы,
2014 елның 20 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы,
2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы,
2016 елның 22 февралендәге 8-ТРЗ номерлы,
2016 елның 3 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы
Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны үз вакытында ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыруның аерым мәсьәләләрен җайга сала.

2 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Күпфатирлы йорттагы урын милекчесе (алга таба шулай ук – урын милекчесе) үзенә карый торган урынны тоту чыгымнарын башкарырга, шулай ук торак урынны тоту өчен түләү һәм күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнәр (алга таба – капиталь ремонт өчен кертем) кертү юлы белән күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне тоту чыгымнарында бу мөлкәткә гомуми милек хокукындагы үз өлешенә карап катнашырга тиеш.

*(2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонтка чыгымнар күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт фонды (алга таба – капиталь ремонт фонды) акчалары исәбеннән, Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яисә) җирле бюджет акчалары исәбеннән һәм закон белән тыелмаган башка чыганаклардан финанслана.

3. Урыннар милекчеләре, Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очраклардан тыш, әлеге Законның 9 статьясы нигезендә бил-



Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләр өчен түләү;

эш бирүче тарафыннан үз хезмәткәрләренә, шул исәптән инвалидлык яки яшь буенча пенсиягә чыгуга бәйле эштән киткән элеккеге хезмәткәрләренә матди ярдәм;

авторлык хокукы һәм катнаш хокуклар турындагы, шул исәптән мирас буенча авторлык шартнамәләре турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә авторга түләнә торган акчалар;

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүдән керемнәр, моңа крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге, шул исәптән юридик зат булмыйча гына хуҗалык итү нәтиҗәсендә алынган керемнәр дә керә;

акцияләр буенча керемнәр һәм оешма милке белән идарә итүдә катнашудан кергән башка керемнәр;

алына торган алиментлар;

банк кертемнәре буенча процентлар;

мирас һәм бүләк ителгән акчалар;

гражданнарга социаль ярдәм чаралары буларак бирелә торган һәм торак урыны, коммуналь яки транспорт хезмәте күрсәтүләргә түләүгә бәйле булган акчалата түләүләр;

торак урынына, коммуналь һәм транспорт хезмәте күрсәтүләргә түләү буенча гражданнарга бирелә торган Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар тарафыннан билгеләнгән ташламаларның һәм социаль ярдәм чараларының гражданнарга түләүләрне киметү рәвешендә бирелгән акчалата эквивалентлары;

торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен гражданнарның аерым категорияләренә түләнә торган компенсацияләр;

опекага алынган затны карап тору өчен опекунга (попечительгә) бүлеп бирелә торган акчалар;

мәгариф оешмаларында мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының укуларына түләү өчен теләсә кайсы чыганаклардан җибәрелгән акчалар (мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының үз акчаларыннан гайре);

*(2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

гражданнарның төрле категорияләренә ай саен акчалата түләүләр һәм компенсацияләр суммалары, алар түбәндәге законнар нигезендә билгеләнә:

«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы;

«Ветераннар турында» Федераль закон;

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон;

«Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль закон;

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль закон;

дәүләт социаль ярдәме буларак бирелгән суммалар.

11 статья. **Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләмен билгеләгәндә исәпкә алынмый торган керемнәрнең төрләре**

1. Гражданнарның керемнәренә түбәндәгеләр кертелми:

кеше гомеренә һәм сәламәтлегенә, аның шәхси мөлкәтенә һәм гаилә әгъзаларының уртак милкендәге мөлкәткә китерелгән зыянны каплауга бирелә торган бер тапкыр түләнүче иминият түләүләре, шулай ук дәүләт медик-социаль экспертиза хезмәте учреждениесе карары нигезендә медицина, социаль һәм һөнәри реабилитациягә өстәмә чыгымнарга бәйле ай саен түләнә торган суммалар;

әйберләтә ярдәм рәвешендә дәүләт социаль ярдәме турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелә торган дәүләт социаль ярдәме;

*(2008 елның 5 августындагы 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

эш белән тәэмин итү хезмәте тәкъдиме буенча башка җиргә эшкә (укуга) җибәрелүгә бәйле рәвештә эшсез гражданнарга түләнә торган матди чыгымнарны компенсацияләү;

җирләүгә пособие;

гражданнарның төрле категорияләренә түбәндәгеләр нигезендә ел саен бирелә торган компенсацияләр һәм бер тапкыр бирелә торган пособиеләр:

«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы;

«Ветераннар турында» Федераль закон;

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон;

«Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль закон;



өстәмә рәвештә) бәйле башка даими мәҗбүри түләүләргә, күчемле һәм күчемсез мөлкәтне иминләштерүгә) бәйле чыгымнарны кертеп, айлык мәҗбүри түләүләрнең гомуми суммасы;

ДС – гаиләнең уртача айлык җыелма кереме (керем салымын исәпләмичә).

6. Торак урыны алу өчен җитмәгән акчаларны җыю буенча гаиләнең мөмкинлеге түбәндәге формула буенча исәпләнә:

Н = (ДС – СПМ) х ПН, монда

Н – билгеләнгән чорда гаилә җыя ала торган акча күләме;
ДС – гаиләнең уртача айлык җыелма кереме;
СПМ – гаиләгә исәпләгәндә уртача айлык минималь дәрәҗә;
ПН – акча җыюның билгеләнгән чоры (айларда).

7. Гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү.

Әгәр җитми торган акчаларның күләме гаиләнең акча җыю мөмкинлегеннән артык булса (ПЖ > Н), ә уртача айлык җыелма кеременең гаиләнең бер кешесенә туры килә торган күләме торак урыны сатып алу яисә төзү өчен кредит алуга дәгъва итәргә мөмкинлек бирмәсә (П/ДС > 30% яисә О/ДС > 40 %) – мөрәҗәгать итүче гражданны аз керемле дип тану турында карар кабул ителә.

7.1. Әгәр акча җыю буенча гаиләнең мөмкинлекләре җитми торган акчалар күләменә тигез булса яисә артып китсә (Н >= ПЖ) – мөрәҗәгать итүче гражданны аз керемле дип танымау турында карар кабул ителә.

7.2. Әгәр җитми торган акчаларның күләме гаиләнең акча җыю мөмкинлекләреннән артса (ПЖ > Н), әмма гаилә торак урыны сатып алу яисә төзү өчен кредит алуга дәгъва итә алса (П/ДС <= 30%, О/ДС <= 40 %), мөрәҗәгать итүче гражданны аз керемле дип тану яисә танымау турындагы конкрет карар тиешле муниципаль берәмлектә торак урыны сатып алу максатларында торак кредитлары базарының үсеш дәрәҗәсенә бәйле булырга мөмкин. Ул түбәндәгеләр белән билгеләнә:

торак сатып алу кредитларын тәэмин итүче кредит оешмаларының булуы (ипотека, өлешләп төзү, торак-туплау кооперативлары һ.б.);

торак кредитларын субсидияләү буенча региональ яисә муниципаль программаларның булуы;

мөрәҗәгать итүче гражданга торак сатып алу яисә төзү өчен кредит бирү яки бирүдән баш тарту турында банкның конкрет карары.

3. Торак урыны бирү нормасыннан ким булмаган күләмдә торак урыны алу өчен гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның җитми торган акчалары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПЖ = СЖ – И, монда

ПЖ – торак урыны өчен акчага ихтыяҗ;
СЖ – социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алуга базар хакының исәпләнгән күрсәткече;
И – граждан гаиләсенеке булган, салым салынырга тиешле һәм социаль наем шартнамәләре буенча исәпкә кую һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү максатларында гражданнарны аз керемлеләр категориясенә керткәндә исәпкә алына торган мөлкәт хакы күләме.
4. Ипотека кредиты алу мөмкинлеген бәяләү түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПЛТ = ПЖ х ПС / (1 – (1+ПС) – КП), монда

ПЛТ – ипотека кредиты буенча ай саен түләү суммасы;
ПЖ – торак урыны өчен акчага ихтыяҗ;
ПС – кредит буенча айлык процент ставкасы (унарлы вакланма);
КП – кредит түләүнең бөтен чорында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны).
5. П/ДС, О/ДС, ПЖ/СЖ коэффициентларын файдаланып, ПЛТ күләмендә гаиләнең кредитны ай саен түләү мөмкинлеге:

1) П/ДС <= 30%, монда

П – төп бурыч буенча айлык түләүләрне һәм ипотека кредиты буенча процент түләүләрен (ПЛТ), мөлкәткә салымнар буенча айлык түләүләрне, күчемсез мөлкәтне иминләштерү буенча айлык түләүләрне, шулай ук заемщикның гомерен иминләштерүне кертеп, заемщикның айлык торак чыгымнары;
ДС – гаиләнең уртача айлык җыелма кереме (керем салымын исәпләмичә);

2) О/ДС <= 40%, монда

О – турыдан-туры кредитлар түләүгә (П), шулай ук озак сроклы (кагыйдә буларак, бер елдан артык) йөкләмәләргә (куллану кредитларына, башка бурыч йөкләмәләренә, шулай ук алиментларга, тәрбиядәгеләрне карап торуга, сәламәтлекне медицина иминләштерүенә яисә пенсия акчаларына (контрактлар һәм шартнамәләр нигезендә



«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль закон.
2. Түләнгән алиментлар суммасы гаилә кеременнән яисә ялгыз яшәүче граждан кеременнән төшереп калдырыла.
3. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керемне исәпләгәндә тору урыннарында түбәндәгеләрнең керемнәре исәпкә алынмый:
сержантлар, старшиналар, солдат яисә матрослар буларак чакырылу буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең, шулай ук хәрби һөнәри мәгариф оешмаларында һәм югары белем хәрби мәгариф оешмаларында белем алучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләрнең;
*(2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*
иректән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтүче затларның, сак астында тоту рәвешендәге җәза чарасы кулланылган, шулай ук суд карары буенча мәҗбүри дәваланудагы затларның;
интернат тибындагы учреждениеләрдә тулысынча дәүләт тәэминатында яшәүче затларның;
хәбәрсез югалган һәм эзләүдәге затларның.
4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән гражданнар өчен аларның булу урынына бәйле булмаган керемнәре (банклардагы, бүтән кредит учреждениеләрендәге кертемнәр буенча керемнәр, күчемле һәм (яки) күчемсез мөлкәтне наемга яки поднаемга бирүдән керемнәр, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бүтән керемнәр) исәпкә алына.

12 статья. **Аерым категорияләрдәге гражданнарның керемнәрен билгеләү үзенчәлекләре**

1. Хезмәткә сәләтле балигъ булган гражданнар гаризада үзләренең керемнәрен, шул исәптән хезмәт һәм (яки) индивидуаль эшкуарлык эшчәнлегеннән дә, хисап чорының бер генә ае өчен дә раслый алмаган яисә мөстәкыйль декларация тапшыра алмаган яки керемнәренең булмавын раслаучы документлар тапшырган очракларда хисап чоры дәвамында керемнәре булмаганнар дип танылалар.
Урта һөнәри яисә югары белем мәгариф оешмаларында белем алучылардан тыш, хисап чоры дәвамында керемнәре булмаган дип танылган хезмәткә сәләтле балигъ булган гражданнар гаилә әгъзаларының гомуми составыннан төшереп калдырыла. Бу очракта гаиләнең уртача айлык җыелма кереме гаилә әгъзаларының гомуми санына түгел, ә хи-

сап чорында керемнәре булмаган хезмәткә сәләтле балигъ булган гражданнар санына киметелгән гаилә әгъзалары санына бүленә.

*(2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Әгәр гражданнар үз керемнәренең нинди дә булса төрләрен, хезмәт һәм индивидуаль эшкуарлык эшчәнлеге керемнәреннән тыш, документлар нигезендә раслый алмасалар, аларга мондый керемнәрне гаризада мөстәкыйль декларацияләү хокукы бирелә.

3. Салым салуның гомуми йә гадиләштерелгән системасын, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен салым салу системасын (бердәй авыл хуҗалыгы салымын) кулланучы индивидуаль эшкуарларның керемнәрен индивидуаль эшкуарларның керемнәрен һәм чыгымнарын, хуҗалыкның эш-гамәлләрен исәпкә алу кенәгәсендәге белешмәләр белән раслау зарур, ул, кәгазьдә язылып, вәкаләтле органга тапшырылырга тиеш.

Тиешле чыгымнар күләменә киметелмәгән керемнәр салым салу объекты булып торса, индивидуаль эшкуарлар хисап чорына чыгымнарны раслаучы беренчел исәпкә алу документларын тапшыралар. Вәкаләтле орган кирәк булганда индивидуаль эшкуарларның керемнәрен һәм чыгымнарын, хуҗалыкның эш гамәлләрен исәпкә алу кенәгәсеннән өземтәләр ясарга яки битләренең күчермәләрен яисә бөтен кенәгәнең күчермәсен бирүне таләп итәргә хокуклы.

4. Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәй салым рәвешендәге салым салу системасын кулланучы индивидуаль эшкуарларның керемнәре, декларация кабул итү турында салым органы тамгасы куелып, узган салым чорындагы салым декларацияләренең күчермәләре белән расланалар.

5. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасының керемен исәплләгәндә, хезмәт хакын, хезмәт өчен түләү системасы белән каралган һәм эш нәтиҗәләре буенча бер айга түләнә торган компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне, ай саен түләнә торган социаль түләүләрне һәм башкаларны кертеп, барлык керемнәрнең суммасы хисап чорына керүче фактта алынган айда исәпкә алына.

6. Компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, хезмәт хакын исәпләүнең һәм түләүнең бүтән сроклары билгеләнгән булса, алынган хезмәт хакы суммасы, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне кертеп, әлеге эш хакы исәпләнгән айлар санына бүленә һәм граждан керемнәрендә хисап чорына туры килүче айларда исәпкә алына.

7. Срокле хезмәт шартнамәләре буенча башкарыла торган сезонлы, вакытлы һәм башка төр эшләргә түләү, граждан-хокукый характердагы шартнамәләрне үтәүдән керемнәр, шулай ук эшкуарлыктан һәм бүтән эшчәнлектән керемнәр суммалары аларны алган айлар санына бүленә һәм гражданнар керемнәрендә хисап чорына туры килә торган айларда исәпкә алына.



хакы буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме;

СЖ – социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алуга базар хакының исәпләнгән күрсәткече;

ПС – кредит буенча айлык процент ставкасы (унарлы вакланма);

КП – кредитның барлык чорында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасының һәм фатир хакының нисбәте;

0,3 – кредит буенча түләүнең һәм гаиләнең айлык җыелма кеременең нисбәте;

б) торак урыны алу өчен ипотека кредиты алу мөмкинлеге булмаган муниципаль берәмлекләрдә – гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләнгән хакы буенча торак урыны алуга акчалар җыю өчен кирәкле уртача айлык җыелма керем күләменнән чыгып, монда шушы муниципаль берәмлектә акчалар җыюның билгеләнгән уртача чоры исәпкә алына, ул социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны алуга чират көтүнең уртача вакытына тигез рәвештә кабул ителә. Бу чакта Татарстан Республикасында билгеләнгән уртача яшәү минимумына тигез яисә аннан кимрәк керем булганда акча җыюның башкарыла алмавы исәпкә алына.

Бу очракта гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләмен билгеләү өчен түбәндәге формула кулланыла:

ПД = (СЖ / ПН) / РС – ПМ, монда

ПД – гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык керемнең иң чик күләме;

СЖ – социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алуга базар хакының исәпләнгән күрсәткече;

ПН – акча җыюның билгеләнгән чоры (айларда), ул социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны алуга чират көтүнең уртача вакытына тигез булырга мөмкин;

РС – гаилә әгъзалары саны;

ПМ – бер кешегә җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән керемнең уртача айлык минималь дәрәҗәсе (гаиләнең бер әгъзасына яшәү минимумы яисә керемнең башка минималь дәрәҗәсе (мәсәлән, икеләтелгән яшәү минимумы).

Муниципаль берәмлектә халыкның яшәү өчен социаль кулай стандартларны тәэмин итә торган керемнәре күләмнәрен исәпкә алып, бер кешегә исәпләнгән минималь керем дәрәҗәсен билгеләргә тәкъдим ителә.

«Татарстан Республикасы
дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль
торак фондыннан социаль наем шартнамәләре
буенча гражданнарның аларга торак урыннары
бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

## Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы

1. Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алуга базар хакының исәпләнгән күрсәткече (алга таба – исәпләнгән күрсәткеч) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$СЖ = НП \times РС \times РЦ,$$ монда

СЖ – социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алуга базар хакының исәпләнгән күрсәткече;

НП – әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзалары саны;

РЦ – бер квадрат метр торак урыны мәйданының әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешенә туры килә торган уртача исәпләнгән базар бәясе, ул Татарстан Республикасында торак урыны алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен федераль башкарма хакимиятнең тиешле органы тарафыннан гомуми мәйданның бер квадрат метрына билгеләнгән уртача базар хакыннан артмаска тиеш.

2. Мөлкәт хакының иң чик күләме СЖ торак урыны базар хакының исәпләнгән күрсәткеченә тигез рәвештә кабул ителә.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган иң чик уртача айлык җыелма керем түбәндәгечә билгеләнә:

а) торак урыны алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләнгән хакы буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнән чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ПД = 0{,}7 \times СЖ \times ПС / (1 - (1+ПС) - КП) / (0{,}3 \times РС),$$ монда

ПД – гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләнгән



8. Гражданнар – крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзалары тарафыннан алынган керемнәр законнарда билгеләнгән тәртиптә әлеге хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган уңышлардан, продукциядән һәм керемнәрдән файдалану турында крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзалары арасында төзелгән килешүдә (шартнамәдә) билгеләнгән күләмнәрдән чыгып исәпкә алына.

9. Күчемсез һәм бүтән төрле мөлкәтне арендага (наемга, субарендага, поднаемга) бирүдән алынган керем суммасы аны алган айлар санына бүленә һәм хисап чорына туры килүче айларда гражданнар керемнәрендә исәпкә алына.

10. Гражданнар тарафыннан белешмәләр бирелгән керемнәр законнар нигезендә барлык салымнарны һәм җыемнарны түләгәннән соң кала торган күләмдә исәпкә алына.

13 статья. **Аерым категорияләрдәге гражданнарның керемнәрен исәпкә алу һәм мөлкәтләре хакын билгеләү үзенчәлекләре**

1. Бөтен хисап чоры яисә аның өлеше дәвамында мәгариф һәм бүтән оешмаларда, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, тәрбиягә алган гаиләләрдә, гаилә тибындагы балалар йортларында, ялгыз яшәүче ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның күрсәтелгән учреждениеләрдә яшәгән айлардагы керемнәре тиешле социаль-демографик төркемнең яшәү минимумына тигез дип санала.

*(2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Хисап чоры дәвамында чакырылу буенча хәрби хезмәтне сержантлар, старшиналар, солдатлар яки матрослар буларак үтүче хәрби хезмәткәрләр, шулай ук хәрби һөнәри мәгариф оешмаларында һәм югары белем хәрби мәгариф оешмаларында белем алучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләр арасыннан булган ялгыз яшәүче мөрәҗәгать итүчеләрнең; иректән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтүче затларның, сак астында тоту рәвешендәге җәза чарасы кулланылган затларның; суд карары буенча мәҗбүри дәваланудагы затларның; судның закон көченә кергән карары нигезендә хәбәрсез югалган дип танылган затларның; тору урыннарында тулысынча дәүләт тәэминаты алып интернат тибындагы учреждениеләрдә яшәүче затларның керемнәре, әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, тиешле социаль-демографик төркем өчен яшәү минимумына тигез дип тан578ыла.

*(2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Әлеге статьяның 1, 2 өлешләрендә күрсәтелгән затлар үзләренең законлы күчемсез мөлкәтләренең үз файдалануларына күчә алмавы турындагы белешмәләрне раслаган очракларда (суд низаглары, билгелән-

гән тәртиптә хокук теркәлгән торак урынына чынбарлыкта кереп урнашу мөмкинлеге булмаган, күрсәтелгән затның үз мөлкәте өлешен сату мөмкинлеге булмаган очракларда, бүтән чикләүләр булганда), аның күчемсез мөлкәтенең хакы нульгә тигез дип таныла. Мөлкәттән файдаланып булмау турындагы белешмәләрне раслау тиешле документлар нигезендә гражданның тору урынындагы опека һәм попечительлек органнары яисә вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

14 статья. **Һәр гражданга туры килә торган керем күләмен билгеләү**

1. Һәр гражданга туры килә торган керем күләме тапшырылган документлар һәм белешмәләр нигезендә әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле орган тарафыннан исәпләнелә.

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Гаиләнең һәр әгъзасының яисә ялгыз яшәүче мөрәҗәгать итүче гражданның уртача айлык кереме хисап чоры дәвамында алынган керемнәр суммасын бу керемнәрне алган айлар санына бүлү юлы белән исәпләнелә.

Гаиләнең һәр әгъзасының уртача айлык керемнәре суммасы хисап чорында гаиләнең уртача айлык җыелма керемен тәшкил итә.

3. Хисап чорында гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем хисап чорында гаиләнең уртача айлык җыелма керемен мөрәҗәгать итүче гражданның гаилә әгъзалары санына бүлү юлы белән исәпләнелә.

4. Хисап чорында һәр гражданга туры килә торган уртача айлык керем күләменең хисап чорындагы айлар санына һәм гаилә әгъзалары санына тапкырчыгышы хисап чорында гаиләнең җыелма керемен тәшкил итә.

15 статья. **Гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында исәпкә алына торган мөлкәт**

1. Гражданнарны аз керемлеләр дип тану өчен гражданнар милкендәге һәм Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә кабул ителгән салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе субъектлары законнары, җирле салымнар һәм җыемнар турында муниципаль берәмлекләрнең норматив хокукый актлары нигезендә салым салынырга тиешле мөлкәт хакы исәпкә алына.

2. Гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында исәпкә алына торган мөлкәткә түбәндәгеләр керә:

торак йортлар, фатирлар, дачалар, гаражлар һәм бүтән төзелмәләр, урыннар һәм корылмалар;



3) торак урынын сату-алу шартнамәсен суд тәртибендә гамәлгә яраксыз дип тану.

*(4 өлеш 2011 елның 13 декабрендәге 101-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

5. Торак урынына мохтаҗ буларак исәптә тору хокукын алу максатларында гражданның үз торак шартларын начарайту нияте, әгәр үз көченә кергән суд карары белән башкасы билгеләнмәгән булса, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гамәлләрне кылган көннән алып биш ел үткәнчегә кадәр исәпкә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итү факты буенча билгеләнә.

*(5 өлеш 2011 елның 13 декабрендәге 101-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

28 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән ун көн узгач үз көченә керә һәм 2005 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев**

Казан, Кремль,
2007 елның 13 июле
№ 31-ТРЗ

2. Торак урыннары бирелер алдыннан гражданнар вәкаләтле органга әлеге Законның 6 статьясында каралган документларны, шулай ук социаль наем шартларында торак урыны алганнан соң элек биләгән мәйданны бушату турында, булган торак урынына өстәп торак урыны бирелү очракларыннан тыш, гаиләнең балигъ булган әгъзаларының язма йөкләмәсен кабат тапшырырга тиеш.

27 статья. **Гражданнарның үз торак шартларын белә торып начарайту нәтиҗәләре**

1. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын алуны ниятләп, нәтиҗәдә торак урыннарына мохтаҗлар итеп танылa алырлык гамәлләр кылган гражданнар белә торган шундый гамәлләр кылган көннән биш елдан соң гына торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алыналар.

2. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирелгәндә, били торган торак урыннарының мәйданын киметүгә яисә бетерүгә китергән гамәлләр һәм торак урыннары белән граждани-хокукый алыш-бирешләр кылу исәпкә алына. Күрсәтелгән алыш-бирешләр һәм гамәлләр гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирелгәнчегә кадәрге биш ел вакыт эчендә исәпкә алына.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән очракта бирелә торган торак урынының гомуми мәйданы социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасыннан чыгып исәпләнелгән гомуми мәйдан белән гаилә әгъзалары саны һәм граждан (аның гаилә әгъзалары) әлеге гамәлләрне һәм граждани-хокукый алыш-бирешләрне кылган гамәлдә булган торак урынының гомуми мәйданы арасындагы аерма белән билгеләнә.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гамәлләргә түбәндәгеләр керми:

1) гражданнарның гаилә әгъзаларын яшәү урыны буенча урнаштыру, әгәр урнаштырганчы алар:

а) элеккеге яшәү урыны буенча торак урыныннан мөстәкыйль файдалану хокукына ия булмаган булсалар;

б) элеккеге яшәү урыны буенча гаиләнең бер әгъзасына торак бирү нормасыннан кимрәк мәйданлы торак урыныннан социаль наем шартнамәсе буенча файдалану хокукына ия булган булсалар;

в) элеккеге яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урынына ия булган булсалар;

г) элеккеге яшәү урыны буенча торак урынын дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә түләүсез тапшырган булсалар;

2) гомерлек рента һәм гомерлек тәрбиядә тоту шартнамәсен рента алучы инициативасы белән өзү, торак урынын рента алучыга кире кайтарып;



законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән автомобильләр, мотоцикллар, мотороллерлар, автобуслар һәм башка үзйөрешле машиналар һәм пневматик, чылбырлы йөрешле механизмнар, самолетлар, вертолетлар, теплоходлар, яхталар, паруслы суднолар, катерлар, снегоходлар, моточаналар, моторлы көймәләр, су мотоцикллары, үзе йөрми торган (буксирлана торган суднолар) һәм башка су һәм һава транспорты чаралары;

торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативларындагы пай җыелмалары;

*(2015 елның 16 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

*бишенче абзац үз көчен югалтты;*

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

мөлкәт һәм җир өлешләре (пайлары) хакы, валюта хакы һәм валюта хакында белдерелгән кыйммәтле кәгазьләр;

муниципаль берәмлекнең Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә җир салымы кертелгән территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре.

16 статья. **Гражданнарның гомуми өлешле милкендәге яисә гражданнарның һәм юридик затларның гомуми өлешле милкендәге йә гомуми уртак милектәге мөлкәтне исәпкә алу үзенчәлекләре**

Салым салу объекты итеп танылa торган мөлкәт берничә гражданның гомуми өлешле милкендә яки гражданнарның һәм юридик затларның гомуми өлешле милкендә булса, шулай ук салым салу объекты итеп танылa торган мөлкәт берничә физик затның гомуми уртак милкендә булса, гражданнарны аз керемлеләр категориясенә керткәндә мондый гражданның һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә салым түли торган мөлкәте исәпкә алынырга тиеш.

17 статья. **Хисап чоры дәвамында сатылган мөлкәтне исәпкә алу үзенчәлекләре**

Салым салынырга тиеш һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында гражданнарны аз керемлеләр дип тану өчен исәпкә алына торган мөлкәт исемлегенә керә торган мөлкәт гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче мөрәҗәгать итүче граждан тарафыннан хисап чоры дәвамында сатылган булса, сатылган мөлкәтнең хакы, гражданнар мөрәҗәгать итүче тапшыра торган тиешле документлар белән расланган мәҗбүри сату очракларыннан тыш (ашыгыч медицина дәвалануы, кыйммәтле дарулар һәм башкалар өчен түләү), хисап чоры дәвамында булган мөлкәт хакы буларак исәпкә алына.

18 статья. **Гражданнар милкендәге күчемсез мөлкәтнең хакын билгеләү тәртибе**

1. Гражданнар милкендәге күчемсез мөлкәт хакын күчемсез мөлкәтне кадастр исәбенә алуны һәм аның дәүләт кадастрын алып баруны гамәлгә ашыра торган органнан тиешле салым органнары тарафыннан алынган белешмәләр нигезендә вәкаләтле орган билгели. Граждан яисә вәкаләтле орган күчемсез мөлкәтнең кадастр хакы белән килешмәгән очракта мөлкәтнең базар хакы кулланыла, бу очракта күчемсез мөлкәтне бәяләү буенча тиешле чыгымнарны кадастр хакы белән килешмәгән зат түли.

*(2015 елның 16 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Җир кишәрлекләренең хакы җирнең кадастр хакы турындагы белешмәләр нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

*(2015 елның 16 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

19 статья. **Гражданнар милкендәге транспорт чараларының хакын билгеләү**

Гражданнар милкендәге һәм исәпкә алынырга тиешле транспорт чаралары хакы транспорт чараларына гражданнарның үз акчалары исәбеннән үткәрелә торган бәяләү турында бәяләү эшчәнлеге субъекты хисабы нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

20 статья. **Гражданнар мөлкәтенең бүтән төрләренең хакын билгеләү**

1. Торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативларында пай җыелмалары хакын билгеләү мөрәҗәгать итүче граждан тарафыннан бирелгән һәм торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативлары тарафыннан таныкланган белешмәләр нигезендә башкарыла.

*(2015 елның 16 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. *Үз көчен югалтты.*

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

21 статья. **Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирелүгә хокукны кабат раслау максатларында гражданнар керемнәренең күләмен һәм мөлкәтенең хакын яңадан бәяләү**

1. Социаль наем шартнамәләре буенча аз керемлеләр буларак үзләренең статусын һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннары



тапшырылган яисә соратып алынган документларда чынбарлыкка туры килми торган һәм исәпкә алу өчен нигез булган белешмәләр барлыгы, шулай ук исәпкә алу турындагы мәсьәлә хәл ителгәндә вәкаләтле органның вазыйфаи затлары тарафыннан хокуксыз гамәлләр кылу ачыкланса.

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Исәптән төшерү вәкаләтле орган карары нигезендә мондый карарны кабул итүгә нигез булып торучы хәлне ачыклаган көннән утыз эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптән төшерү турында карарлар мондый исәптән төшерүнең нигезләрен үз эченә алырга тиеш. Гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптән төшерү турындагы карарлар аларны кабул иткән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча үзләренә карата мондый карарлар кабул ителгән гражданнарга бирeләләр яисә җибәреләләр, һәм аларга карата күрсәтелгән гражданнар тарафыннан суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган нигезләр буенча исәптән төшерелгәннән соң гражданның торак урыны алуга мохтаҗ буларак исәпкә куелу хокукы яңадан барлыкка килсә, исәпкә куелу гомуми нигезләрдә башкарыла.

4. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак вәкаләтле орган тарафыннан яшәү урыны буенча исәпкә куелган һәм социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча башка муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан торак урыннары бирелүгә бәйле рәвештә яшәү урынын үзгәрткән гражданнар торак урыннарына мохтаҗлар буларак аларның элекке яшәү урыны буенча исәптән төшерелергә тиеш түгел.

*(2015 елның 16 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

26 статья. **Торак урыны бирелү турында гражданга хәбәр итү тәртибе һәм, социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында карар кабул ителгәндә, гражданнарны исәпкә алуга таләпләр**

1. Социаль наем шартнамәләре буенча гражданга торак урыны бирелү турында вәкаләтле орган карары үзенә карата әлеге карар кабул ителгән гражданга, әгәр социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирелү хокукына ия гражданнарның башка категорияләрен билгеләүче федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары, Татарстан Республикасы законнары белән башкасы каралмаган булса, әлеге карар кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

торак урынына мохтаҗлык статусын раслый торган түбәндәге документлар кирәк:

әгәр узган чорда элек тапшырылган белешмәләрдә үзгәрешләр барлыкка килмәсә, граждан вәкаләтле органга элек үзе тапшырган белешмәләрнең үзгәрмәвен раслый торган тиешле расписка тапшырырга тиеш;

әгәр узган чорда граждан турындагы белешмәләр составында үзгәрешләр барлыкка килсә, граждан вәкаләтле органга шундый үзгәрешләрнең булуы турында хәбәр итә. Раслый торган документларны тапшыру бурычы әлеге Законның 6 статьясы нигезендә билгеләнә. Мондый очракта вәкаләтле орган гражданны торак урынына мохтаҗ буларак кертүнең нигезле булуын кабат тикшерә.

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4. Әгәр яңадан теркәлү барышында гражданның торак урынына мохтаҗлыгы статусын раслый торган нигезләргә ия булмавы ачыкланса, вәкаләтле орган, әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән документлар бирелгән һәм (яисә) документларның тулы комплекты соратып алынган көннән алып утыз көннән дә соңга калмыйча, гражданның социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗлыгы статусы югалу турында карар кабул итә. Гражданның торак урынына мохтаҗлыгы статусы югалу турындагы карар гражданга әлеге карар кабул ителгән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла яисә җибәрелә.

*(4 өлеш 2008 елның 5 августындагы 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде, 2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

### 25 статья. **Гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптән төшерү**

1. Гражданнар торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптән түбәндәге очракларда төшереләләр:

исәптә тору урыны буенча исәптән төшерү турында гариза бирсәләр;

социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны алу хокукын бирә торган нигезләр юкка чыкса;

яшәү өчен башка муниципаль берәмлеккә күчеп китсәләр;

дәүләт хакимияте органыннан яисә җирле үзидарә органыннан торак урыны сатып алу яисә төзү өчен билгеләнгән тәртиптә бюджет акчалары алсалар;

аларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органыннан яисә Татарстан Республикасы җирле үзидарә органыннан торак йорт төзү өчен билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлеге бирелсә, моңа өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнар керми;

*(2012 елның 29 сентябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*



алуга хокукын раслау максатларында исәпкә куелган гражданнарның керемнәрен һәм мөлкәтенең хакын яңадан бәяләү вәкаләтле орган тарафыннан ел саен 1 гыйнвардан 1 майга кадәрге чорда әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

*(2008 елның 5 августындагы 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Әгәр гражданнар тиешле документларны үз инициативалары белән тапшырмасалар, яңадан бәяләү уздыру өчен вәкаләтле орган әлеге Законның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган документларны (граждан тарафыннан бирелә торган гаризадан тыш) агымдагы елның 1 апреленә кадәр соратып алырга тиеш.

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Аз керемлеләр дип танылган гражданнарның керемнәре күләмен һәм мөлкәтенең хакын яңадан бәяләү түбәндәгечә башкарыла:

керемнең һәм мөлкәт хакының иң чик күләме кимегәндә, гражданнарны исәпкә алган вакытта гамәлдә булган кыйммәтләр кулланыла;

керемнең һәм мөлкәт хакының иң чик күләме артканда, керемнең һәм мөлкәт хакының яңа гына билгеләнгән иң чик күләмнәре кулланыла.

4. Керемнәрнең күләме һәм мөлкәтнең хакы керемнәрнең яисә мөлкәт хакының иң чик күләмнәренә тигез яки артып киткән дәрәҗәсенә кадәр үскән очракта, гражданнар үзләрендә, аз керемлеләр статусын алу өчен кабаттан мөрәҗәгать итү хокукын саклап калып, әмма исәптән төшерү вакытына карата киләсе хисап чорыннан да иртәрәк булмаган вакытка аз керемлеләр статусын югалталар. Гражданның аз керемле статусын югалтуы турындагы карар вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Законның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган документлар бирелгән көннән бер айдан да соңга калмыйча мөстәкыйль кабул ителә. Гражданның аз керемле статусын югалтуы турындагы карар гражданга әлеге карар кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла яисә җибәрелә.

*(2008 елның 5 августындагы 67-ТРЗ номерлы, 2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

5. Хисап чорында теге яки бу салым буенча салым салу базасын исәпләгәндә салым салынырга тиешле мөлкәт исемлеген киңәйтү юлы белән салымнар һәм җыемнар турындагы законнарга үзгәрешләр кертелгән очракта, вәкаләтле орган элек аз керемлеләр категориясенә кертелгән гражданнарга салымнар һәм җыемнар турындагы законнарга кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә хисап чорында теге яки бу салым буенча салым салу базасын исәпләгәндә салым салынырга тиешле мөлкәтнең булуы турында вәкаләтле органга язмача белдерергә кирәклек турында хәбәр итә. Гражданнарда мондый мөлкәт булган очракта, алар тиешле документларны үз инициативалары белән тапшырмасалар, вәкаләтле орган салым салынырга тиешле һәм гражданнар милкендә

булган мөлкәтнең гомуми хакын кабат билгеләү өчен мондый мөлкәтнең хакы турындагы белешмәләрне законнар нигезендә шул белешмәләр белән эш итүче дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан өстәмә рәвештә соратып ала.

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6. Тиешле салымнарны юкка чыгарганда яки мөлкәтне салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә салым салынырга тиеш мөлкәт исемлегеннән төшереп калдырганда вәкаләтле орган салым салынырга тиешле һәм гражданнар милкендәге мөлкәтнең гомуми хакын кабат билгели.

**22 статья. Гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында яки гражданнарны аз керемлеләр дип танудан баш тарту турында карарлар кабул итү**

1. Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында гражданнар вәкаләтле орган карары нигезендә аз керемлеләр дип таныла.

2. Вәкаләтле орган тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән гражданнар аз керемлеләр дип танылган булып санала.

3. Вәкаләтле орган тарафыннан гражданнарны аз керемлеләр дип танудан баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Законның 6 статьясында каралган документларны, вәкаләтле орган тарафыннан соратып алына торган документлардан тыш, тапшырмау;

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

гражданнар тапшырган документларда ялган мәгълүмат булу һәм (яисә) мәгълүмат тулы булмау;

мөлкәти хәлен исәпкә алып, гражданнарны аз керемлеләр дип тану өчен нигезләрнең булмавы;

гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар дип тану өчен нигезләрнең булмавы.

**23 статья. Гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алудан баш тарту**

1. Гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алудан баш тарту түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

*(2010 елның 24 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

әлеге Законның 6 статьясында каралган документлар, вәкаләтле орган тарафыннан соратып алына торган документлардан тыш, тапшырылмау;



*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының йә дәүләт хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы оешманың ведомствоара гарызнамәгә җавабы, әгәр тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса, гражданнарны әлеге Законның 6 статьясы нигезендә торак урыннарына мохтаҗ сыйфатында исәпкә алу өчен кирәкле документ һәм (яисә) мәгълүмат булмавын таныклый, моңа мондый соратып алына торган документның яисә мәгълүматның шушы органнар яисә оешмалар карамагында булмавы тиешле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар сыйфатында исәптә тору хокукын раслый торган очраклар керми;

*(өченче абзац 2012 елның 29 сентябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу хокукын расламаучы документлар тапшырылу һәм (яисә) соратып алыну;

*(2012 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы, 2012 елның 29 сентябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

гражданнар торак урыннарына мохтаҗлар буларак танылырга мөмкин булган гамәлләр кылган көннән законнарда билгеләнгән вакытның чыкмавы.

*(2012 елның 29 сентябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алудан баш тарту турындагы карар, баш тартуның нигезен күрсәтеп, гражданнарга әлеге карар кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә яисә җибәрелә, һәм граждан аңа карата суд тәртибендә шикаять белдерергә мөмкин.

**24 статья. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торучы гражданнарны яңадан теркәү**

1. Гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукы алар социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары алганчы яисә әлеге Законның 25 статьясындагы 1 өлешендә каралган исәптән төшерү нигезләре ачыкланганчы сакланып кала.

2. Вәкаләтле органнар ел саен 1 гыйнвардан алып 1 майга кадәрге чорда торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торучы гражданнарны яңадан теркиләр.

*(2008 елның 5 августындагы 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Яңадан теркәлү өчен 1 апрельгә кадәр, әлеге Законның 21 статьясы нигезендә керемнәр күләмен һәм мөлкәт хакын яңадан бәяләү өчен тапшырыла яисә соратып алына торган документлар белән бергә,